## ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ:

**кемнәргә кагыла, чакыру кәгазьләре ничек тапшырыла?**

> 2–3

## МИН – ДАҺИ!

**Балаларның сәләтләрен үстерү аларга зыянга да булырга мөмкин**

> 15

## ЛИЛИЯ МӘХМҮТОВА:

**«Уйналмаган рольләр бик күп калды»**

> 18


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 139 (28912) | Җомга | 23 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

metshin.ru

# ФАЙДАЛЫ ГАДӘТ

## ӘЙЛӘНӘ-ТИРӘНЕ ҮЗГӘРТҮНЕ ҮЗЕҢНӘН БАШЛАРГА КИРӘК

**Табигатькә, экологик вазгыятькә битараф булмаганнар тирә-якны үзгәртүне иң элек үзеннән башлый. Гади һәм җиңел адымнардан. Әмма күпләрнең анысын да ясыйсы килми. Сәбәпләре дә бар: вакыт җитми, нәтиҗәсен күрми, кирәк дип тапмый. Чүп-чар җыюга бәйле вазгыять тә шул сәбәпләр тирәсендә әйләнә. Барысын да бер кучкә өеп кую агын – акка, карасын карага бүлеп утыруга караганда җиңелрәк бит. Әмма моңа киртә куймагайлары.**

> 6

### Ишетми калмагыз

Россиядә өлешчә мобилизация игълан ителгәннән соң ялган сайтлар һәм мошенниклардан электрон хатлар бик нык арткан. «Коммерсант» басмасы хәбәренә караганда, кешеләргә армиядән, мобилизациядән котылып калуга, тиз генә чит илгә чыгып китүгә ярдәм итү, ялган медицина белешмәләре бирү тәкъдим ителә.

Белгечләр әйтүенчә, мошенниклар ялган сайтлар аша гына да эш итми әле. Алар хәрби хезмәткә чакырылучыга яки якыннарына теге яки бу ярдәм тәкъдим итеп, телефон аша шалтыратыра, хат-хәбәр, исемлеккә кертелү-кертелмәвеңне белү өчен вируслы кушымталар да җибәрергә мөмкин.

1 гыйнвардан аз керемле гаиләләр универсаль пособие ала башлаячак. Аның гамәлдәге берничә түләүне, шулай ук бала туугга бәйле, сабыйга 3 яше тулганчы бирелә торган пособиеләрне берләштерүе күздә тотыла. Россия Премьер-министры Михаил Мишустин белдергәнчә, универсаль пособие 3–7 яшьлек һәм 8–17 яшьлек балаларга түләүләрне дә үз эченә алачак. Ул шулай ук йөкле мохтаҗ хатын-кызларга биреләчәк.

Пособие алу өчен бер генә гариза тапшырырга кирәк. Аны Дәүләт хезмәтләре порталы аша, шулай ук Күпфункцияле үзәккә яки Социаль иминиятләштерү фондына барып тапшырырга мөмкин.

Исегезгә төшерәбез: быел 3–8 яшьлек балаларга айлык түләүгә тагын 8дән 18 яшькә кадәргеләр өчен яңа пособие өстәлде. Ул һәр балага түләнә. Түләүнең илдәге уртача күләме 11592 сум тәшкил итә. Төбәкләрдә – 11341 сумнан 30784 сумга кадәр.

Яшел Үзән районының Айшә авылында 3D принтер технологияләре буенча «Квадрум» торак комплексы төзелә. Россиядә тәүге шундый бистә булачак бу. Районның матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, биредә йортлар роботның «кран-кулы» ярдәмендә төзелә: ул бетон катнашмасын катламлап урнаштырып бара. Принтер корылманы санаулы көннәр эчендә торгыза.

Район хакимияте башлыгы Михаил Афанасьев әйтүенчә, робот эшне нык җиңеләйтә: төзүчеләр бик аз таләп ителә, эшләр тиз һәм бернинди калдыксыз диярлек башкарыла. 3D принтер йортны 21 көн эчендә төзеп бетерә. Инновацион технологияләр нигезендә корылган өйдән 80–120 ел дәвамында файдаланырга мөмкин. Озакламый мондый төзелешнең киң таралуы күздә тотыла.

Якын көннәрдә Татарстанда һава температурасы акрынлап төшәчәк. Татарстан Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне күзәтү идарәсеннән хәбәр ителгәнчә, шимбә – 24 сентябрьдә кайбер районнарда аз гына яңгыр көтелә. Көндез +19...+24, төнге сәгатьләрдә +9...+14 градус җылы. Якшәмбе – 25 сентябрьдә явым-төшем көтелми. Көндез һава температурасы +13...+18 градустан артмаячак, яңгыр булыр дип фаразлана. Төнлә термометрның терекөмеш баганасы +7...+12 градус күрсәтәчәк.

## ВЛАДИМИР ПУТИН:

# «СЕЗНЕҢ ЯРДӘМЕГЕЗГӘ ЫШАНАМ»

**«Безнең тарихи традициябездә, халкыбыз язмышында дөнья белән хакимлек итүгә омтылган, Ватаныбызга аны таркату һәм коллыкка төшерү белән янаганнарны туктату бар. Без хәзер дә шуны эшлибез, шулай булачак та. Сезнең ярдәмегезгә ышанам». Россия Президенты Владимир Путин ил халкына мөрәҗәгать итеп, өлешчә мобилизация кертелү турында игълан иткәндә әнә шулай диде. Әлеге яңалык кемнәргә кагыла?**


kremlin.ru

### Көтелгән мөрәҗәгать

14 минут һәм 21 секунд дәвам иткән мөрәҗәгатендә Россия Президенты бүгенге вазгыять турында сөйләде һәм бу шартларда дәүләтнең ни эшләргә җыенганын җиткерде. «Сүз Россиянең мөстәкыйльлеген, куркынычсызлыгын һәм территориаль бөтенлеген яклау буенча кирәкле, ашыгыч адымнар турында, ватандашларыбызның үз киләчәген билгеләргә омтылуы һәм ихтыярына ярдәм итү, Көнбатыш элиталарының агрессив сәясәте турында бара», – диде ул. Владимир Путин ассызыклаганча, Көнбатышның максаты – Россияне көчсезләндерү, бүлгәләү һәм юкка чыгару: «Алар 1991 елда ук Советлар Союзын җимерә алуларын, ә хәзер Россиягә дә вакыт җиткәнен турыдан-туры әйтәләр. Ул үзара дошманлашып яшәячәк төбәкләргә һәм өлкәләргә бүленергә тиеш, диләр». Ил башлыгы әйтүенчә, алар тоталь русофобияне үз коралы итте, дистә еллар дәвамында Россиягә карата нәфрәт тәрбияләде, 2014 елда ук сугыш башлап, Украина халкыннан корбан ясады.

Россия Президенты әйтүенчә, ЛНР неонацистлардан инде тулысынча диярлек чистартылган, ДНРда бәрелешләр дәвам итә: анда катлаулы саклану линиясе корылган. Владимир Путин сүзләренә караганда, маңгайга-маңгай бәрелешеп, штурмга бару зур югалтуларга китерер иде. Шуңа күрә безнең частьлар, Донбасс республикаларының хәрби подразделениеләре планлы, акыллы рәвештә хәрәкәт итә. Сугышчыларны саклыйлар һәм акрынлап Донецк җирен азат итәләр.

### «Битараф кала алмыйбыз»

Махсус хәрби операция башлангач, мәсьәләне тыныч юл белән хәл итүгә ниндидер өметләр барлыкка килсә дә, Владимир Путин фикеренчә, Көнбатышны мондый нәтиҗә канәгатьләндерми. Шулай итеп, Украинага тагын да күбрәк корал тутыра башладылар. Киев режимы чит илдән ялланып килүчеләр һәм милләтчеләрнең яңа бандаларын, НАТО стандартлары буенча һәм Көнбатыш киңәшчеләре кулы астында өйрәтелгән хәрби частьларны эшкә җикте. Украинада куркыту, террор һәм көч куллану сәясәте тагын да куркынычрак төсмер ала. «Якын кешеләребезне палачлар кулына бирергә бернинди хакыбыз юк. Аларның үз язмышларын үзләре хәл итәргә чын күңелдән омтылуларына карата битараф кала алмыйбыз», – диде Владимир Путин.

Билгеле булганча, Донбасстагы халык республикаларының парламентлары, Херсон һәм Запорожье өлкәләренең хәрби-халык хакимиятләре үзләрендә бу территорияләрнең киләчәге турында референдум уздыру хакында карар чыгарды һәм бу адымнарын хуплауны сорап, Россиягә мөрәҗәгать итте. Владимир Путин Россия алар кабул иткән карарны хуплаячак дип белдерде.

Ил Президенты Россияне атом-төш коралы белән куркытырга маташуларын да искә алды. Андыйлар белеп торсын: Россиянең НАТОныкыннан да заманчарак кораллары бар. «Илебезнең территориаль бөтенлегенә куркыныч янаганда, Россияне һәм халкыбызны яклау өчен, һичшиксез, безнең карамакта булган барлык чараларны кулланабыз. Бу арттыру түгел», – диде ул.

### Тарихи традиция һәм халык язмышы

Владимир Путин сүзләренчә, Россиянең Кораллы Көчләре неонацистлар гына түгел, берләшкән Көнбатышның хәрби машинасына каршы тора. Әнә шуны исәптә тотып һәм илнең бөтенлеген, халыкның иминлеген яклау һәм саклау өчен Россиядә өлешчә мобилизация уздырыла. Моның өчен башкарыласы чараларны 21 сентябрьдә үк тормышка ашыра башладылар. Махсус указ да шул көнне дөнья күрде. «Безнең тарихи традициябездә, халкыбыз язмышында дөнья белән хакимлек итүгә омтылган, Ватаныбызга аны таркату һәм коллыкка төшерү белән янаганнарны туктату бар. Без хәзер дә шуны эшлибез, шулай булачак та. Сезнең ярдәмегезгә ышанам», – диде Россия Президенты мөрәҗәгатендә.

Владимир Путин ассызыклаганча, хәрби хезмәткә хәзерге вакытта запаста торучы, барыннан да бигрәк Кораллы Көчләр сафында хезмәт иткән, хәрби-учет белгечлекләре һәм тиешле тәҗрибәсе булганнар чакырылачак. Частьларга китәр алдыннан алар өстәмә хәрби әзерлек узачак. Мобилизациягә эләккән кешеләр акча түләү, социаль гарантияләр мәсьәләсендә контракт буенча хезмәт итүчеләр белән бер дәрәҗәдә булачак. Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру өчен төбәк башлыклары җавап тотачак.

### Фикер

**Альфред ВӘЛИЕВ, «Коммунисты России» сәяси партиясе рәисе урынбасары, Казан шәһәр Думасы депутаты:**

– Башкомандующий игълан иткән өлешчә мобилизацияне мин дә, безнең партия оешмасы да уңай бәялибез. Бу – дөрес карар. Ул безнең сугышчыларның да, тыныч халыкның да гомерен саклап калырга ярдәм итәчәк, Украинада денацификация һәм демилитаризация бурычларын тизрәк һәм нәтиҗәлерәк тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк. Запастагы офицер буларак, әнә шуңа ышанам. Дусларым һәм танышларым арасында Россия Президентының бу карарын уңай бәяләмәгән бер генә кеше дә юк. Ә алар арасында хәрбиләр дә, шул ук вакытта армиядә бөтенләй хезмәт итмәүчеләр дә бар. Хәрби хәрәкәтләрдә катнашу тәҗрибәсе булган кешеләр мондый карарның кирәклеген тагын да яхшырак аңлый. Хәер, гади кешеләр дә вазгыятьне, илебезне, кеше гомерләрен саклап калу өчен башка юл булмаганын күреп тора. Фашизмга каршы көрәш – безнең уртак эшебез һәм изге бурычыбыз.

**Вениамин ЧУБАРЕНКО, Ветераннарның «Боевое братство» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстандагы төбәк бүлеге советы рәисе урынбасары:**

– Миңа калса, бу карарны бераз иртәрәк тә кабул итәргә кирәк булгандыр. Мөгаен, җитәкчеләребез суверенитетларын үз аяклары белән таптап, Америка артыннан ияргән илләрнең саны шулкадәр күп булыр дип уйламагандыр. Бөтен Европа төп көндәшебезгә ярдәм иткәндә, безгә дә хәрби контингентны арттырырга кирәк. Шунсыз булмый. Һәм ул бер гаепсез кешеләрнең гомерен коткару хакына эшләнә. Миңа калса, россиялеләрнең күпчелеге мобилизация игълан итүне тыныч кабул итәр. Шулай кирәк тә. «Мобилизация» сүзеннән куркасы түгел. Ул курку сугыш елларыннан ук калган инде. Ләкин хәзерге вакытта мобилизацияне сугышка таба бер адым буларак кабул итәргә кирәкми. Әйткәнемчә, махсус хәрби операциягә бәйле вазгыять катлаулангач, безгә хәрбиләребезнең санын арттырырга кирәк. Швеция һәм Финляндия НАТОга керә, ә НАТО илләренең Россия белән гомуми чиге – бер мең километр тирәсе. Әлеге илләр нейтраль булып саналганда, Россия анда гаскәрләр тотмады. Ләкин хәзер ул бу территорияләргә гарнизоннар куярга мәҗбүр.

### Сүз уңаеннан

**Россиянең оборона министры Сергей Шойгу сүзләренә караганда, өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылачак кешеләрне запастагылар арасыннан сайлап алалар. Армияне беркайчан да күрмәгән-ишетмәгән кешеләр турында сүз бармый. Бу хакта ул «Россия 24» каналында әңгәмәсендә әйтте.**

#### Министр тагын нинди фикерләр җиткерде?

★Россиядә тиешле таләпләргә туры килгән 25 миллион чамасы кеше бар. Өлешчә мобилизация исә аларның 1 процентына гына кагыла. Бу – 300 мең чамасы кеше дигән сүз.
★Мобилизациягә эләккәннәр исә азат ителгән территорияләрне контрольдә тоту белән шөгыльләнәчәк.
★Чакырылыш буенча хезмәт итүчеләр махсус хәрби операция зонасына җибәрелми: алар Россия территориясендә хезмәт итүләрен дәвам итәчәк.
★Студентларны хәрби хезмәткә чакырырга җыенмыйлар. «Тынычлап укырга йөрсеннәр», – диде армия генералы.

## *Татарстанда да тавыш биреп була*

Донецк һәм Луганск халык республикаларында, Херсон, Запорожье өлкәләрендә референдум көннәрендә Татарстанның өч шәһәрендә сайлау участоклары ачылачак. Бу хакта Үзәк сайлау комиссиясе Рәисе Андрей Кондратьев комиссия утырышында белдерде.

«Донецк һәм Луганск халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләре җитәкчелеге Россия Федерациясе составына керү мәсьәләсе буенча референдумнар үткәрү турында карар кабул итте. Тавыш бирү биш көн – 23–27 сентябрьдә узачак. Россиянең бөтен сайлау системасы Донецк һәм Луганск халык республикалары, Херсон һәм Запорожье өлкәләре сайлау комиссияләренә ярдәмгә киләчәк. Татарстанның өч шәһәрендә сайлау участоклары эшләячәк. Алар Казанда, Чаллы һәм Әлмәттә ачылачак», – диде ул. Андрей Кондратьев билгеләп үткәнчә, Казандагы сайлау участогының берсе – «Сәйдәш» концерт залында, Әлмәттә – «Нефтьче» мәдәният йортында, Чаллыда – «Родник» та эшләячәк.

Сүз уңаеннан, 23 сентябрьдә – ДНР, ЛНР, Херсон һәм Запорожье өлкәләрендә референдумнар башлану көнендә республиканың иҗтимагый һәм патриотик оешмалары Җиңү паркында митинг уздыра. Патриотик митинг «Үзебезнекеләрне ташламыйбыз» шигаре астында уза. Акция катнашучыларны ватандашларга, Россия Президенты һәм Россия Кораллы Көчләренә теләктәшлек белдерүдә берләштерә. Көндезге сәгать 3тә башланасы чарада иҗат коллективлары, шул исәптән һава десанты гаскәрләренең (ВДВ) «Голубые береты» ансамбле чыгыш ясаячак.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӘРБИ КОМИССАРЫ БОЕРЫГЫ

21 сентябрь, 2022 ел Казан ш. № 183

**Мобилизация игълан итү турында**

Россия Федерациясе Президентының 21 сентябрь, 2022 ел, № 647 Указы нигезендә, 2022 елның 21 сентябре 09 сәгать 00 минуттан Татарстан Республикасы территориясендә өлешчә мобилизация игълан ителде.

**БОЕРЫК БИРӘМ**:

§ 1

Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, мобилизацион боерыкларга (мобилизационное предписание) ия булучы яки муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатларыннан шәхси повесткалар алучы запастагы барлык офицерларга, прапорщикларга, мичманнарга, сержантларга, старшиналарга, солдатларга һәм матросларга шәхси повесткаларда күрсәтелгән срокта һәм шунда күрсәтелгән пунктларга килергә, ә шәхси повесткалар алмаган очракта – мобилизацион боерыкларда күрсәтелгән срокта һәм шунда күрсәтелгән пунктларга килергә.

Татарстан Республикасы территориясендә вакытлыча яшәүче запастагы гражданнарга хәрби учетка куелу урыны буенча хәрби комиссариатка үзләренең кайда булуларын күрсәтергә.

§ 2

Мобилизацион боерыкка ия булмаган һәм муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатларыннан повесткалар алмаган запастагы офицерларга, прапорщикларга, мичманнарга, сержантларга, старшиналарга, солдатларга һәм матросларга чыгып китү-кайту тәртибен хәрби учетка куелу урыны буенча хәрби комиссариатларда килештерергә.

§ 3

Бу боерыкның 1 параграфы нигезендә чакырылучы запастагы офицерларның, прапорщикларның, мичманнарның, сержантларның, старшиналарның, солдатларның һәм матросларның, мобилизация буенча килгәндә, мобилизацион боерыкларда һәм шәхси повесткаларда күрсәтелгән документлары һәм шәхси әйберләре булырга тиеш.

§ 4

Оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, оешмалар җитәкчеләренә, бу боерыкның 1 параграфы нигезендә чакырылучы гражданнарны эштән һәм хезмәттән азат итәргә, алар белән тулысынча исәп-хисап ясарга, аларга хезмәт хакын түләргә һәм, мобилизацион боерыкларда һәм шәхси повесткаларда күрсәтелгән срокта һәм шунда күрсәтелгән пунктларга килүләрен тәэмин итәргә.

§ 5

Оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, оешмалар җитәкчеләренә, транспорт чараларына ия булучы гражданнарга, аерым боерык нигезендә, төзек автомобильләрен, юл төзелеше транспортын, күтәргечле транспортны һәм башка машиналарны һәм механизмнарны муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатлары нарядларында күрсәтелгән срокта һәм шунда күрсәтелгән пунктларга китереп куярга.

§ 6

Мобилизация буенча үзләренә күрсәтелгән срокта һәм күрсәтелгән пунктларга килмәгән Россия Федерациясе гражданнары һәм муниципаль берәмлекләрнең хәрби комиссариатлары нарядлары буенча транспорт чараларын билгеләнгән срокта китереп куймаган, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, оешмалар җитәкчеләре, шулай ук транспорт чаралары хуҗалары яки мобилизация буенча гражданнарның үз вакытында килүенә һәм транспорт чараларын китереп куюына комачаулаучылар Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

§ 7

Бу боерыкны, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, барлык оешмаларда игълан итәргә һәм аңлатырга.

Татарстан Республикасы
хәрби комиссары С. Погодин

«Татар-информ»

## ӨЛЕШЧӘ МОБИЛИЗАЦИЯ ТУРЫНДА 5 СОРАУГА ҖАВАП

**1. Өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру кәгазьләре ничек тапшырыла?**

– Повестканы хәрби комиссариат хезмәткәре яки эш урынында тапшыралар. Мобилизацион боерыклар (мобилизационное предписание) яки повесткада күрсәтелгән урынга вакытында килеп җитәргә кирәк. Сүз уңаеннан, хәрби хезмәткә чакырылучыларга повестканы Дәүләт хезмәтләре порталы аша юллау турындагы сүзләр дөреслеккә туры килми. Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы әнә шундый хәбәр җиткерде. Казан урамнарында повестка өләшү турындагы хәбәрләр дөреслеккә туры килми.

**2. Күрше шәһәргә яки районга, чит илгә чыгып китәргә ярыймы?**

– Әгәр мобилизацион боерыклар (мобилизационное предписание) яки повестка тапшырылмаган икән, берничә көнгә чыгып китәргә ярый. Яшәгән урыныгызга озаграк кайтмый торырга җыенасыз икән, бу хакта хәрби комиссариатка белдерергә кирәк. Чил илгә чыгучыларга килгәндә, хәрби учетта торучыларга комиссариатка барып, сәфәр чыгуның сәбәпләрен һәм аның күпме вакытка сузыласын аңлатырга туры киләчәк. Хәрби учетта тормаучыларга, әйтик, сәламәтлеге аркасында, андый таләп куелмый.

**3. Чакырылган вакытка хәрби комиссариатларга бармаучыларны кем эзләячәк?**

– Бу эш белән эчке эшләр органнары шөгыльләнә.

**4. Өлешчә мобилизация буенча Татарстаннан ничә кешене хәрби хезмәткә чакырачаклар?**

– Бу сан чикләнгән мәгълүмат булып санала.

**5. Кораллы Көчләрне тулыландыру өчен гади халык кулындагы техниканы алачаклармы?**

– Шәхси техниканы алмаячаклар. Предприятиеләрдә исә армия ихтыяҗы өчен тапшырылырга мөмкин техника буенча аерым наряд бар. Бу техника да кешеләр кебек үк учетта тора. Аларны махсус карар буенча алалар. Хәзерге вакытта предприятие җитәкчесе үзләрендәге нарядны ачыкларга һәм техниканың төзеклеген тикшерергә тиеш. Кеше машинасын урамда ук алып китәчәкләр дигән хәбәрләр дөреслеккә туры килми.

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**Россия Федерациясе сенаторы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органыннан вәкил вәкаләтләре бирү турында**

«Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советын формалаштыру тәртибе турында» 2020 елның 22 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **карар бирәм**:

1. Россия Федерациясе сенаторы – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органыннан вәкил вәкаләтләрен Терентьев Александр Михайловичка бирергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль, 2022 ел, 22 сентябрь, № ПУ-656

tatarstan.ru

# КИЛЕШҮ НОКТАСЫ

**Хезмәттәшлек**

**Казанда Беларусь Республикасы делегациясе рәсми сәфәр кылды. Бу илнең Премьер-министр Роман Головченко җитәкчелегендә килгән кунаклар Татарстан вәкилләре белән ике арада хезмәттәшлекне үстерү турында сөйләште. Башкалада Казанда «Татарстан – Беларусь» эшлекле форумы узды.**

Сәфәрнең беренче көнендә Роман Головченко белән Президент Рөстәм Миңнеханов Казан Кремлендә очрашып сөйләште. Очрашуда ике арадагы элемтәләрне тагын да файдалырак итеп үстерү хакында фикер алыштылар. «Белоруссия безнең өчен стратегик партнер һәм безнең үзара хезмәттәшлек өчен зур резервыбыз бар. Безнең дәүләтләр арасында үзара аңлашу хөкем сөрә, һәм без хезмәттәшлегебез өчен яңа урыннар табарга тырышачакбыз», – диде Рөстәм Миңнеханов. Аның сүзләрен Роман Голченко хуплады. «Эш һәм бизнеста, дәүләт хезмәтендә уңышның төп билгесе – тотрыклы рәвештә үсә торган товар әйләнеше. Бу безнең үзгәргән шартларга бик тиз ияләшә алуыбызга бәйле». Аның сүзләренчә, бүгенге вазгыять тизрәк хәрәкәт итүгә һәм моңа кадәр игътибар җитмәгән эшләргә алынырга этәрә.

«Татарстан – Беларусь» эшлекле форумы да әлеге сөйләшүнең дәвамы булды. Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Беларусь Татарстанның чит илдәге төп партнерларыннан берсе булып тора һәм товар әйләнеше буенча лидерлар исәбенә керә. Әлеге күрсәткеч якынча 1 миллиард доллар тәшкил итә. Моннан тыш Татарстан белән Беларусь арасындагы элемтәләрне ныгытуга гамәлдәге килешүләр, делегацияләр белән даими алышулар, шулай ук уртак эш төркеме эшчәнлеге ярдәм итә. Татарстан Президенты әйтүенчә, уртак эшчәнлек күрсәткечләре әйбәт булуга карамастан, Татарстан – Беларусь хезмәттәшлеген үстерүдә файдаланылмый килгән мөмкинлекләр дә бар әле. «Халыкара шартлар катлаулы булган бер мәлдә предприятиеләребезнең уртак эшчәнлеген көчәйтергә, кече һәм урта бизнесны ыграк җәлеп итәргә кирәк. Республикабызның икътисади мөмкинлекләренең Беларусь предприятиеләре өчен кызыклы булачагына өметләнәбез», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Беларусь делегациясен көн дәвамында Татарстандагы икътисад, инвестицияләр һәм инновацияләр өлкәсендәге яңалыклар белән таныштырдылар. Кунакларны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин озатып йөрде. Алар Бәшир Рәмиев исемендәге ИТ-паркта булдылар. Бередә кунакларны йөртүчесез идарә ителә торган КФУ-МТЗ-112 тракторы каршы алды. Ул «МТЗ-Татарстан» белән берлектә КФУ исәпләү математикасы һәм мәгълүмат технологияләре институты тарафыннан эшләнгән. Әлеге трактор дистанцион режимда махсус эшләнгән программа белән тәэмин итү аша оператор тарафыннан идарә ителә.

Республикада эшләүче технопарклар, махсус икътисадый зоналар һәм социаль-икътисадый үсеш территорияләре инвесторларны күптәннән җәлеп итә. Бу хакта кунакларга Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгында сөйләделәр. Анда делегация вәкилләренә республиканың һәм район-шәһәрләрнең икътисади һәм инвестицион потенциалын тәкъдим иттеләр.

– Әлбәттә, Россия Федерациясенең барлык 85 субъекты да инвестицияләр кертү буенча көндәшлек итә, – дип сөйләде агентлык җитәкчесе Талия Миңнуллина. – Әмма без Татарстанны Россия базарына керү нокталарының берсе буларак күрсәтәбез, һәм ул, Мәскәү белән чагыштырганда, шактый арзанга төшә.

Әйтеп кенә бактым

## Озату

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Россия Президенты өлешчә мобилизация игълан иткәч, бер танышым: «Армиягә чакыру килсә, нишләр идең?» – дип сорады. Ул моны шаяртыбрак әйтте үзе, әмма йөзендә моңсулык күрдем. Шулай да: «Чакырсалар барам, кәнишне, яшең туры килеп бетми дисәләр генә», – дип елмайгандай иттем.

Моннан төгәл 50 ел элек Риман абыегызны солдатка озатканнар иде инде. Бер уйлаганда, мин армиягә алынырга тиеш түгел идем. Университетта хәрби кафедра булып, һәрберебезгә лейтенант дәрәҗәсе бирәләр иде. Ни сәбәпледер, миңа хәрби дәрәҗә бирү турында приказ килеп җитмәгән булган. Шуңа күрә язгы матур көннәрнең берсендә хәрби комиссариатка чакырып кулга повестка тоттырдылар да: «Рядовой булып хезмәт итәрсең», – диделәр. «Есть!» – дигән булдым да чыгып киттем инде. Авылга кайтып, әти-әниғә повестканы күрсәттем. Алар артык борчылмый-дулкынланмый гына озату кичәсенә әзерләнә башладылар...

Озаттылар мине. Әни: «Йөзебезгә кызыллык китермә, улым!» – диде. Әти: «Барып җиткәч, хат язарга онытма!» – дип өстәде.

Ул еллардагы матур гадәт буенча дуслар белән авыл урамнарын җырлап әйләндек. Икенче көнне иртүк иң якын дуслар белән колхоз машинасына утырдык та:

«Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сау булыгыз туганнар», –

дип кульяулык болгый-болгый, җырлап авылдан чыгып киттек.

Казанга, хәрби комиссариатка чакырган вакытка килдем дә, 3 нче бүлек башлыгы бүлмәсенә кереп: «Военнообязанный Гилемханов по повестке прибыл», – дидем. Майор: «Как прибыл, так и убыл», – дип сөйләнә-сөйләнә чакыру кәгазен кәрҗингә ыргытты да: «Ты свободен! На тебя приказ пришел», – диде. Дөресен әйткәндә, мин югалып калдым. Оят иде миңа. Майорга авылда озату кичәләре үткәреп, әти-әни, дуслар белән саубуллашуым турында сөйли башладым. Баксаң, 1972 елгы язгы чакыруда офицерлар алу нормасы үтәлгән икән. Ә мин: «Рядовой булып хезмәт итәрмен», – дип карыйм. Майор: «Не положено!» – дип кырт кисә. Офицерны рядовой итеп армиягә алу закон бозу була икән.

Хәрби комиссариаттан чыктым чыгуын, тик кая барырга белмим. Авылга кайту турында уйлау да юк инде ул. «Солтан малаен армиягә яраксыз дип браковать иткәннәр», – дигән сүз таралачак. Безнең заманда хәрби хезмәткә яраксыз дип табылу хурлык санала иде шул. Андыйларга хәтта кызлар да шикләнеп карады.

Без бит сугыш турында кинолар карап, үзебез ясаган агач мылтыклар, кылычлар белән «сугыш-сугыш» уйнап үскән буын. Минем дә армиягә китәсе, тагын да чынысы, берәр батырлык күрсәтеп, берәр медаль тагасы килә иде. Бәлки, капитан погоннары да эләгер иде әле...

Шул вакытларны искә төшереп, хәзерге көн турында уйланам. Такташның «Безнең хисләр сездә кабатланмас, сез ул хисләр белән янмассыз...» дигән шигъри юллары күңелгә кереп ала. Без дә каршылыклы бер чорга килеп кердек. Һәм бу чор кешеләре дә иң зур идеаллар өчен, шул ук шагыйрь язганча, «җирдә зур дау алып барырга» мәҗбүр. Без:

«Туфрагына алтын чәчсәләр дә,
Җитми икән туган җирләргә», –

дип юкка гына җырламыйбыз.

Тормыш ничек кенә үзгәрмәсен, дөнья ничек кенә буталмасын, Ватан ватан булып кала. Тукай әйтмешли, «Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл».

Туган җиргә мәхәббәт, Ватанны саклау хисләре һәркем күңеленә мәңгелеккә кереп урнашкандыр инде ул.

# КАЯ БАРА СОҢ, ДӨНЬЯ?

pixabay.com

**Соңгы айларның һәм көннәрнең ашкын тизлектә агучы вакыйгалары, башка тимер таяк белән суккан кебек тәэсир итә торган хәлләр һәм карарлар күңелләрдә «Ни өчен болай?» дигән сорау уятмый калмыйлар, чөнки аларның мантыйгын табып булмый.**

Кешелек дөньясы фаталь рәвештә фаҗигале адымнар атлый. 20 сентябрьдә генә Сербия Президенты Вучич бер-ике ай эчендә Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң күрелмәгән зур конфликт башланып китү ихтималы барлыгын игълан итте. Хәер, 2022 елга фаразларда ук без ул конфликтның кай төбәкләрдән үсеп чыгачагын анык итеп әйткән идек һәм фаразларыбызның тормышка ашуын чәчләр үрә торган хәлдә күзәтәбез. Тик Вучич халыкара лидерлар клубына керә һәм анда мәгълүмат төгәлрәк. Әмма дә ләкин бу язмада мин кешеләрне булачак дәһшәтле хәлләр белән куркытырга җыенмыйм. «Ни өчен шулай һәм ни эшләргә?» дигән сорауларга өлешчә җавап бирергә генә тырышырмын. Бу юллар авторына күптән инде кешеләр: «Без ярый яшәдек инде, балалар, оныклар бар бит, аларны афәтләрдән ничек сакларга?» – дигән сорауларны еш бирәләр.

Вакыйгалар һәм хәлләр исә кешеләрнең рухи халәтенә, күңелләренең каралыгына-чисталыгына бәйле рәвештә формалаша. Ахырзаман илчесе Мөхәммәд (салләллаһу галәйһи вә сәлләм) бу хакта: «Минем өммәтемнең иң яхшы вәкилләре – минем белән бер чорда яшәүчеләр, алардан соң – аннан соң килүчеләр, алардан соң – тагын аннан соң килүчеләр. Соңыннан шундый кешеләр килә: күрәләр, әмма шаһитлек бирмиләр (иман китермиләр дип аңлыйк), хыянәт итәләр һәм тугрылык сакламыйлар, вәгъдә бирәләр, әмма үтәмиләр һәм алар арасында юанлык һәм симезлек тарала», – ди. Кыямәт якынлашуның бер билгесен шәрехләүче хәдистән бик яхшы күренә: иман зәгыйфьләнү, адәм балалары арасында ышаныч бетү, таянырлык кешеләр аз калу белән симезлектән интегүче кешеләр саны арта, ягъни рухи халәт физик халәткә әйләнә.

Газета хәбәрчесе, бу юлларны язганда, онлайн режимдагы дөнья статистикасын ача һәм бүген Җир шарында 1 миллиард 733 миллионнан күбрәк кешенең артык авырлыктан интегүен күрә. Бу – һәр дүрт-биш кешенең берсе дигән сүз. Симезлеге туры мәгънәсендә чиргә әйләнгән һәм шуннан җәфа чигүчеләр саны 818 миллионнан артык һәм бу санга секунд саен диярлек бер-ике кеше өстәлеп тора. Симезлек эпидемия кебек тарала дигән сүз бу. АКШта бүген ярты көн эчендә (бу юллар төш вакытында язылa) симезлек дигән чиргә каршы көрәшү өчен 102 миллион доллардан артык акча тоттылар. Сумма шулай ук секунд саен үзгәреп тора һәм тәүлек ахырына ике тапкыр артыр дип уйлыйбыз. Чиргә каршы зур акча тотып көрәшү нәтиҗәләр бирми, күңел чисталыгыннан башка бу чирдән котылып булмый. Симезлектән котылу өчен, хыянәтсез кергән хәләл малдан гына чамасын белеп файдаланырга кирәк.

Кыямәт якынлашуның без игътибар итмәгән тагын бер билгесе – тел ярдәмендә ризыкланучылар. Хезмәт хакы сүз сөйләүгә бәйле булган дистәләгән профессия вәкиле пәйда булды соңгы гасырларда. Болар – адвокатлар, укытучылар, пропагандистлар, артистлар, депутатлар, сенаторлар, конгрессменнар... Профессияләрнең күбесе тыелмый тыелуын, әмма ялган ант бирү, тиеш булмаган кешеләрне чамасыз ялган мактау һәм шуның ише рөхсәт ителмәгән башка ысуллар белән байлык туплау гаепләнә. Профессияләрнең күбесе коррупцион керемнәргә дә юл ача, яисә башкаларга билгеле булмаган мәгълүматлардан файдалану нәтиҗәсендә мал арттыру мөмкинлеге бирә. Соңгы көннәрдә генә «Нью-Йорк таймс» газетасы 97 америкалы сенаторның инсайдер сәүдәсе аша зур байлыклар туплавы хакында язып чыкты. Август аенда гына Кытай белән Тайвань арасында зур сугыш китереп чыгаруга сәбәпче була язган Нэнси Пелоси дигән карчык бар бит әле. АКШ Конгрессының вәкилләр палатасы спикеры. Аның ире июль башында Nvidia компаниясе акцияләрен сатып алган, чөнки хатынының «Чиплар турында закон» эшләвен белгән. Закон Nvidia акцияләренең кыйммәтләнүенә китергән. Үзен гаделлек һәм демократия өлгесе итеп тәкъдим итәргә яратучы Пелоси ханымның яраткан ире җиңел генә байлыгын арттырган да куйган. Хатының тел бистәсе булса, баюның шундый юллары да ачыла ала икән. Конгрессменнар һәм сенаторлар халыкка билгеле булмаган яшерен мәгълүматка (инсайдка) ия, шул аларга фонд сәүдәсендә кул җылытырга мөмкинлек бирә. Бу тыелган, әлбәттә, әмма нәфес тыелган дигән сүзгә бик буйсынмый бит. Менә шундый гаделсезлекләр өсте-өстенә җыелып, зур конфликтларга китерә дә инде.

Кыямәтнең соңгы вакытларда күзәтелә торган тагын бер билгесенә игътибар итәргә киңәш бирер идем мин. Ул – кисәк үлемнәрнең артуы. 2020 елда коронавирус пандемиясе тарала башлаганнан соң, спорт ярышлары вакытында спортчыларның кисәк егылып үлүләре аеруча күп күзәтелә. Гади кешеләр дә тиктомалдан үләләр дә китәләр. Пандемиягә кадәр дә бар иде андый хәлләр. Хәзер күпкә артты. Канада докторы Роджер Ходкинсон бу хакта: «Өлкәннәрнең кисәк үлем синдромы хәзерге вакытта иң таралган үлем сәбәбенә әйләнеп бара. Бу кешеләрнең күбесе инсульттан, йөрәк өянәгеннән, диабеттан үлгәнгә караганда ешрак үлә. Элек андый хәл күзәтелми иде», – ди.

Хәзерге заман Мәккәсенә барган кешеләр күрәләр: таулар-кыялар эчендә утырган шәһәр кварталлары тоннельләр белән тоташып беткән, йортларны тауларны кисеп төзиләр. «Әгәр син Мәккәнең тоннельләр (каналлар) белән ергаланып бетүен һәм тау түбәләреннән ашкан йортларны күрсәң, бел: кыямәт көне якын», – ди. Әй, кешеләр, без боларны күрәбез бит инде, шулай булгач, күпме вакыт калган... Соңгы вакыйгаларның дәһшәтле бөтерелүе, тормышның сюрреализмга һәм фантастикага охшаган сюжет буенча үсүе, шулай булгач, гаҗәпмени?

«Нишләргә соң?» дигән сорауга җавап бирергә тырышып карыйк. Атаклы шәех Ибн Тәймия сүзләре белән дәлилләп карыйк җавапны. Без «бәяләр күтәрелә» дип зарланабыз бит әле. Ибн Тәймия әйтә: «Бәяләр күтәрелү кайбер колларның гаделсезлеге нәтиҗәсендә булырга мөмкин, аларның төшүе кайбер кешеләрнең игелегенә бәйле була ала», – ди. Димәк, бәяләр төшсен дисәк, гаделсезлекне туктатып, игелек эшләүгә күчәргә кирәк. Шушы ук рецепт башка бәхетсезлекләрнең кимүенә дә китерә ала. Аллаһның илчесе: «Аллаһ белән ант итәм, сез игелеккә өндәргә һәм тыелганнан тыярга тиешсез, югыйсә Аллаһ сезне җәзага тартуны ашыктырачак, шуннан соң сез Аннан сорарсыз, ләкин Ул сезгә җавап бирмәячәк», – ди. Өскә бәхетсезлекләр ишелеп килүнең бер сәбәбе – игелекне игелекне үзләре генә эшләп, башкаларны игелеккә өндәмәве, гөнаһлардан тыймавы. Андый чакта һәлакәт изгеләрне дә аямый. Бәхетсезлек килгәч, кешеләр Аллаһка ялваралар, әмма җавап ишетмиләр. Безнең бүгенге хәлебез шундый түгелме?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

# ХЫЯЛЛАНУДАН – ЧЫНБАРЛЫККА

**Хыялланган киләчәк түгел – көнкүрешкә әйләнгән бүгенгебез. Мәгълүмати технологияләрнең көндәлек тормышыбызның аерылгысыз өлешенә әйләнүен һәркем сизәдер. Шунысын да әйтик: IT – ул әле телефон, компьютер һәм программистлар гына түгел. Kazan Digital Week халыкара форумында шуны исбатларга тырыштылар. Бизнес, фән, хакимият, икътисад һәм белгечләр очрашкан урында цифрлы чорның яңа һөнәрләре, алда торган бурычлар, яңалык булырдай тәкъдимнәр турында сөйләштеләр.**

tatarstan.ru

**Өмет – сездә**

«Чикләүләр шартларында барыннан да элек эчке мөмкинлекләребезгә, Россия белгечләренең тәҗрибәсенә таянабыз. Кыска вакыт эчендә кимчелекләрне юк итәргә мөмкин. Бу эштә сезгә өметләнәбез», – дип мөрәҗәгать итте Россия Премьер-министры Михаил Мишустин форум катнашучыларына видеоэлемтә аша. Шулай итеп, Хөкүмәт җитәкчесе бу сүзләре белән быелгы форумда кызыл җеп булып сузылган төп мәсьәләне дә билгеләде: киеренке вазгыятьтә тармак нәрсәгә сәләтле һәм аның бәйсезлеген тәэмин итеп буламы?

Михаил Мишустин сүзләрен форумның рәсми ачылышында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та куәтләде.

– Форум кысасындагы чаралар илнең фәнни-техник суверенитеты бурычларын чишәргә юнәлгән, – диде республика җитәкчесе. – Шул исәптән үзебездә программа тәэминаты булдыру, мәгълүмат саклау, югары квалификацияле белгечләр әзерләү, технологик алдынгылыкка чыгу. Әлеге чара Татарстанда өченче тапкыр уза. Чикләүләр чорында аның көн тәртибендә карала торган мәсьәләләре аеруча актуальләшә.

Президент сүзләренә федераль кунак – Россия цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры урынбасары Максим Паршин да кушылды.

– Илнең цифрлаштыру тормышында әлеге форум традицион чарага әйләнеп бара. Бу – илкүләм чара. Бирегә илнең барлык төбәкләреннән вәкилләр җыелды. Бу инде чараның мөһимлеген дә искәртә, – диде ул.

**Тәкъдимнәр бармы?**

«Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгенең форумда катнашучыларның экспозицияләре өчен бүлеп бирелгән мәйданчыгы быел аеруча зур булды. Компанияләрнең саны узган ел белән чагыштырганда икеләтә күбрәк – 200дән артык. Татарстан Президенты һәм башка рәсми затлар республика өчен генә түгел, ил өчен файдалы булырдай проектлар белән танышып чыкты.

«Иннополис» махсус икътисади зонасы генераль директоры Ренат Хәлимов яшь шәһәрнең үсеш нокталары турында бәян итте. «Безнең резидентлар программа тәэминатын әзерләү белән шөгыльләнде. Быел исә аппарат өлешләрен җитештерәбез. Бу – микроэлектроника, дроннар, робот техникасы. Ел азагына кадәр тормышка ашыра торган проектларыбыз бар», – диде ул.

Моннан тыш «Иннополис»та цифрлы мәгълүмат өлкәсенә кагылышлы яңалык та бар: тиздән бирегә мәгълүмат эшкәртү үзәге (ЦОД. – **Авт.**) эшли башлаячак. Ул Идел буенда иң эре үзәкләрнең берсе булачак. Киләсе елда төзеп бетереп, кулланышка тапшырырга исәпләре.

Кунаклар кызыксынып караган тагын бер экспозиция матбугат чараларына бәйле. Президентка TatTVR проектын тәкъдим иттеләр. Гади итеп әйткәндә, бу кушымтага Татарстандагы барлык радио һәм телевидение чаралары сыйган. Республикадагы яңалыклар, тапшырулар белән танышыйм дисәң, дөньяның кайсы почмагында булуыңа карамастан, бер төймәгә басу да җитә.

Чараның генераль партнеры саналган «Летай» операторы замана яңалыгына әйләнгән «акыллы» домофоннар тәкъдим итте. Кешеләрнең йөзен тану гына түгел аның эше. Күргәзмә катнашучылары әйтмешли, «акыллы» домофон куркынычсыз шәһәрнең бер өлеше дә булмагае.

Цифрлы үзгәрешләр медицинада да кирәк. Әйтик, «Связь» проекты йөкле хатын-кызларның сәламәтлеген дистанцион рәвештә тикшереп тору өчен кушымта уйлап тапкан. Бу бала көткән гүзәл затның хастаханә чиратында басып, көн үткәрмәсен өчен дә, табибның даими күзәтүе астында булуы өчен дә бик мөһим. Оештыручылар әлеге проектны тагын да җәелдермәкче: деменция, сирәк очрый торган авырулары булганнарга да ярдәм итәргә телиләр.

**Бәйсезлек эзләп**

Форумның пленар утырышында катнашучылар һәм кунаклар үзебезнекен булдырып, бәйсезлеккә ирешергә мөмкинме дигән сораугa җавап эзләде. 2025 елга кадәр барлык чит ил программаларын үзебезнеке белән алмаштыру мөһим. Бу – ил башлыгы куйган бурыч.

– Дөнья саклаша бара. Бу тармакның мөһимлеген аңлап, бу елны без Татарстанда Цифрлаштыру елы дип игълан иттек. Цифрлы технологияләр икътисадның күбрәк өлкәләрен үз эченә ала бара, халыкның тормыш сыйфатын һәм бизнесның көндәшлеккә сәләтен арттыра, – диде утырышта Рөстәм Миңнеханов. Форсаттан файдаланып, ул катнашучыларга республиканың цифрлы тармакта ирешкән уңышларын да санап үтте.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, Татарстанда дөнья дәрәҗәсендәге IT-үзәкләр булдырылган. Әйтик, беренчесе 2009 елда барлыкка килсә, Цифрлаштыру елында өченче мәйданчык ачылды, аңа беренче совет компьютерларын уйлап табучы Бәшир Рәмиев исеме бирелде. «Ихтыяҗ зур, бу мәйданчык резидентлар белән тулысынча тәэмин ителде диярлек», – диде Президент.

Утырышта мәгълүмат саклау, халык тормышын җиңеләйтерлек проектлар, мошенникларга каршы көрәш һәм рәсми документлар әйләнешен санлаштыру турында да сүз булды. Әйтик, тиздән электрон машина йөртү таныклыгын (сынау рәвешендә), ислам банкингын гамәлгә кертергә (шулай ук сынау рәвешендә) ниятлиләр.

Белгечләр мәсьәләсе дә кузгатылды. Күнекмәләр һәм һөнәрләр үсеше агентлыгы генераль директоры Роберт Уразов санлы дөнья алып килгән яңа белгечлекләрне санап үтте. Баксаң, мәгълүмат базасын чистартучыдан башлап маркетплейсларның менеджеры һәм пилотсыз оча торган аппаратларның операторы булырдай кешеләр кирәк. Кыскасы, IT-тармак – компьютер төймәсенә басып утыру гына түгеллеген инде аңларга вакыт.

Headhunter компаниясенең GR-директоры Виталий Терентьев, IT-тармактагы хезмәт базары – сәләтлеләр өчен көрәш ул, ди. Кризисмы-юкмы – андыйларга кытлык гел булган һәм булачак та.

– Махсус сораштыру эшләдек. Халыкара санкцияләр, чимал кертүгә бәйле чикләүләр, технологияләргә кытлык зур компанияләргә IT-продуктлар җитештерү өчен белгечләр табарга кыенлык тудырды. Компанияләрнең 33 проценты хезмәткәрләрне кабул итүне арттырса, 26 проценты өчен бу күрсәткеч элеккечә калган. Әмма оешмаларның бик зур өлеше авырлыклар кичергән. IT-белгечләрне саклап калу өчен, компанияләрнең өчтән бере хезмәт хакын 10 процентка арттырган, тагын 10 проценты өстәмә түләүләр белән кызыктырган, – диде ул.

Аның сүзләренчә, компанияләр өчен веб-уйлап табучылар, техник ярдәм белгечләре, аналитиклар аеруча кирәк. Яңа продукт җитештерелгән саен, аны сынау, кимчелекләрен юк итү таләп ителә бит.

Пленар утырыштан соң да фикер алышулар дәвам итте. Белгечләр 10 төрле юнәлеш буенча (монда медицина, мәдәният, белем бирү һәм башка тармаклар керә. – **Авт.**) цифрлаштыру мөмкинлекләрен барладылар. Бу инде көтелгән киләчәк тә түгел, яшәешдә йөргән бүгенгебез. Иң мөһиме – кабул ителгән карарлар халыкның тормыш сыйфатын арттырсын да, замана бурычларына җавап бирерлек булсын.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

## КИЛЕШЕП ЭШЛӘҮ НӘТИҖӘСЕ

Кыенлыкларга карамастан, алга атлыйбыз. «Россия банклары – XXI гасыр» халыкара форумында Татарстан Президенты шулай дип белдерде. Казанда уза торган чарада Россия банкы җитәкчелеге, федераль министрлар, Федерация Советы, Дәүләт Думасы вәкилләре, финанс оешмалары әгъзалары, банкларның топ-менеджерлары катнаша.

– Банк системасының тотрыклы эшләве безнең республиканың эш нәтиҗәләрен исбатлый. Сәнәгать буенча без үсештә (9 проценттан артык), тулай продукт буенча үсеш 5 проценттан артык. Узган ел республиканың сәнәгать җитештерүе күләме 4 трлн сум тәшкил итте, быел ул тагын да күбрәк булачак. Әлегә без, барлык кыенлыкларга карамастан, ышанычлы рәвештә алга барабыз. Логистика, комплектация буенча сораулар бар, әмма без аны да хәл итү юлын табабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов, форум катнашучылары алдында чыгыш ясап.

Президент искәрткәнчә, форум хәзерге вазгыятьтә аеруча актуаль. «Банк һәм финанс базарына иң беренчеләрдән булып санкцияләр белән очрашырга туры килде», – дип ассызыклады ул.

Аның сүзләренә караганда, хәзерге вазгыятьтә банк системасы алдында тотрыклылыкны саклау бурычы тора.

– Банк секторы республика үсешендә зур роль уйный. Анда 21 меңнән артык белгеч эшли, алар үзләренең һөнәри осталыклары белән Татарстанның социаль-икътисади тотрыклылыгын тәэмин итә, – диде Президент. – Республикада җәлеп ителгән акча күләме 1,8 трлн сумга җитте. Шуның 800 млрд сумы – халык кертемнәре. Агымдагы вазгыятькә карамастан, алар ел башыннан 6 процентка арткан. Бу кешеләрнең банк системасына ышанычы турында сөйли. Хакимият органнарының һәм банкларның килешеп эшләве нәтиҗәсендә республикада уңай нәтиҗәләргә ирешелде: банкларның өстәмә офислары ачылды; түләү терминаллары урнаштырылды; товарлар һәм хезмәтләр өчен акчасыз түләү мөмкинлеге булдырылды. Банкларны әлеге эштә активрак катнашырга чакырам.

Илдар Мөхәммәтҗанов

# ФАЙДАЛЫ ГАДӘТ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

### Теләмәсәң – түлисең

Чүпне аерып җыю кагыйдәсе кертелгән төбәкләрдә (Россиядә 85 субъектның 45ендә чүп-чарны аерып җыю гамәлдә. – **Авт.**) аны төрләргә аеру һәм махсус контейнерларга күчерү мәҗбүри булырга мөмкин. Федераль дәрәҗәдә шул хакта тиешле проект әзерлиләр. Үзгәрешләрне 2026 нчы елның 1 нче гыйнварыннан гамәлгә кертү ниятләнә, дип хәбәр итә Россия Табигать байлыклары һәм экология министрлыгы матбугат хезмәте. Сүз нинди үзгәрешләр хакында бара соң?

2026 нчы елдан каты коммуналь калдыкларны төрләр буенча бүлү таләбе кулланучылар өчен мәҗбүри булачак дип көтелә. Әлеге кагыйдәне бозган очракта физик һәм юридик затлар өчен Административ хокук бозулар кодексының 8.2 маддәсе буенча җаваплылык каралган.

Бу маддә буенча хәзерге көндә калдыклар белән эш иткәндә әйләнә-тирә мохитне саклауда таләпләрне бозган очракта штрафка тарталар. Физик затларга ул – 2–3, вазыйфаи затлар өчен – 10–30, шәхси эшмәкәрләргә – 30–50, компанияләргә – 100–250 мең сум күләмдә матди җәза. Кабат хокук бозган очракта җәза тагын да кырысрак.

Яңартылган кагыйдәләрдә әйтелгәнчә, икенчел ресурсларны кешеләр махсус билгеләнгән мәйданчыкларга яки җыю пунктларына тапшырырга тиеш. Башкача әйткәндә, энергия алуда, товарлар җитештерүдә яки хезмәт күрсәтүдә кулланырга яки утильләштерергә мөмкин булган калдыкларны тапшыру.

Тәкъдименә күрә чарасы, дигәндәй, чүплекләр җитәрме соң? Федераль министрлык мәгълүматларына күз салсаң, ил күләмендә 2,3 млн чүп контейнеры исәпләнә. Чүп-чарны аерып җыю өчен дигәннәре – 0,29 млн. Гомуми санның 13 проценты дигән сүз.

Үзгәрешләр гамәлгә кергәнче, төбәкләргә әзерләнергә вакыт бар. Моннан тыш, халыкка шундук штраф салырга җыенмыйлар. Бәлки, беренче тапкырда кисәтү белән генә дә чикләнерләр.

Чүп саласы контейнерларга да таләпләр бар. 2026 елга кадәр аларның төсләре түбәндәгечә булырга тиеш: кәгазь өчен – зәңгәр, пластмасса, резина һәм металлолом өчен – кызгылт сары, азык-төлек калдыклары өчен – коңгырт, пыялага яшел төс каралган. Эшкәртелми торган калдыкларны исә соры төстәге бакка саласы.

**САН**



- Макулатура барлык каты калдыкларның якынча 40 процентын тәшкил итә. 100 кг макулатура бер агачны саклап калырга мөмкинлек бирә.
- Кәгазь һәм аннан ясалган әйберләр 7 тапкыр эшкәртелергә мөмкин.
- 2021 ел нәтиҗәләре буенча, илдә калдыкларны төрләргә аеру дәрәҗәсе 43,3 процентка җиткән. 2021 елда төбәкләр хөкүмәттән каралган субсидияләр буенча калдыкларны аерым җыю өчен 62,8 мең контейнер сатып алган иде.

### Гадәткә керерме?

Проектның китек ягына да игътибар итүчеләр бар. Дәүләт Думасының Экология, табигать ресурслары һәм әйләнә-тирә мохитне саклау комитеты рәисе урынбасары Анатолий Грешневиков әйтүенчә, чүп контейнерларын урнаштыру төп мәсьәлә түгел. Әгәр дә төбәкләргә аерым чүп-чар җыюны оештырырга мөмкинлек биреп тә, чүп эшкәртүче предприятиеләр элеккечә аз булып калса, бу яңалыктан әллә ни файда булмаячак. Аның фикеренчә, башта кешеләрне экологик яктан әзерләргә, мәгълүмат бирергә, эшне заводлардан башларга, аннан гына контейнер һәм чүп ташу машиналары турында уйланырга кирәк. Штраф кертү турында исә – иң соңгы чиратта. «Шешәне аерым җыеп, аның чыннан да эшкәртеләсендә кешедә ышаныч булырга тиеш. Чүп-чар җыючы машина килеп, барлык контейнерларны да бер өемгә ташлый икән, кешеләргә ни өчен штраф салырга?» – дигән фикердә депутат.

Аеру түгел кылану. Казан федераль университеты мөгаллиме, эколог Наил Назаров әйтүенчә, чүп-чарны аерып җыю – модага иярү генә түгел, аңлы рәвештә экологик яшәү рәвешенә бер адым ясау да.

– Билгеле, бер кеше берникадәр дәрәҗәдә пластиктан баш тарта, аны икенчел эшкәртүгә тапшыра икән, бу табигатькә өлеш кертү дигәндә, бәлки, шул дәрәҗәдә зур сан да түгелдер. Әмма андыйлар күбәйгән саен, яхшырак, – ди белгеч. – Моннан дистә еллар элек пластиксыз да яшәгәннәр бит. Кайбер илләрдә пластик куллануны хокукый яктан чикли дә башладылар хәтта. Чүп мәсьәләсе – кискен мәсьәлә инде ул. Хәл итә алмасак, чүп өемендә яшәячәкбез.

Эколог булса да, көндәлек тормышта әңгәмәдәшебез пластигын да, башкасын да куллана, билгеле. «Әмма гади кагыйдәләрне истә тоту, үзеңнең кулыңнан килә торганны эшләү дә экологик үзаңны үстерүдә бер этәргеч була ала. Табигатьне саклау һәр кешенең үзеннән тора. Кайчакта тирә-якны сакларга өйрәтүче чаралар булырга тиеш. Үзең белмисең икән, кешегә булса да ияреергә кирәк», – ди ул.

Экоактивист Гүзәл Макарова чүп-чарны төрләргә аерып яшәргә күнеккән. 10 ел шулай инде. Үзе генә түгел, гаиләсе белән табигатькә һәм экологиягә сакчыл карашны алга сөрәләр. Әйтик, соктан калган кәгазь капларны шундук чүплеккә ташламыйлар. Башта су белән чайкыйлар, киптерәләр, җыялар. Шешә белән дә шул ук хәл. Соңрак бу «байлык» эшкәртүгә тапшырыла. Исраф булмасын дип, аңлы куллану, калдыкларны киметү ягын кайгырталар.

– Чүпне җыю культурасы юк. Без өч төргә бүлә белмибез, дистәләгән төргә аерып, чүп тапшырган дәүләтләр бар. Җыйсак та, төрләргә аерсак та, чүп машинасы барысын да бергә алып китә. Гап-гади эшләр әле дә эшләнмәгән. Кем күпме чүп ташлый, шуның өчен генә акча түләсен иде. Бу кешеләрдә чүпкә карашны да үзгәртер иде дип уйлыйм. Киләчәкне кайгырту бездән тора, – дигән фикердә экоактивист.

Экологик акцияләрдә катнашу – табигатькә булышуның берләнбер ысулы түгел. «Будет чисто!» хәрәкәте җитәкчесе Диләрә Сатикова әйтүенчә, табигатьне яратырга өйрәткән башка гадәтләр дә бар. «Чүп-чарны төрләргә аеру, пластик һәм макулатура – беренче гадәт. Киләсе ысул – полигоннарда азык-төлек калдыкларын киметү. Тагын бер файдалы эко-гадәт – аңлы куллану. Әйтик, кибеткә үз пакетың белән бару, алдан ук исемлек төзеп бару, артыгын сатып алмау. Кием өчен дә шул ук хәл. Мин, шәхсән, берничә ай яки бер елга да түзмәгән арзан әйберләргә караганда озак хезмәт итәчәк практик әйберләргә күбрәк өстенлек бирәм», – ди ул.

### Авылларда ничек?

Чүп машинасы үзе килә, каршы барасы да юк. Татарстанның район-авылларында яшәүчеләр чүпне кая урнаштырырга икән дип баш ватып тормый хәзер. Аерып җыю культурасы гына аксый.

Арча районындагы Наласа авылыннан Рамил Мөхетдинов сөйләвенчә, халыктан чүпне атнага бер тапкыр җыеп китәләр. Бу эшне бердәм оператор башкара.

– Акча ягына килгәндә, чүп өчен бер кешегә 108 сум 40 тиен туры килә. Безнең гаиләдә биш кеше. Чүпне кара пакетларга яки капчыкларга тутырып чыгарып куялар. Кайбер кешеләр капка төбенә, ә кайберләре билгеләнгән урынга чыгаралар, – ди ул.

Ә менә Кышкар авылында ике атнага бер тапкыр җыялар икән.

– Пәнҗешәмбе алып китәләр. Бик җайлы, бик рәхәт. Күрше авылларда чүп машинасы атна саен керә, без кечерәк авыл булгач, ике атнага бер генә инде. Бер айга 104 сум түлисе. Чиста, матур, су буйлары да чистарды хәзер, – диде шушы авылдан Ләйсән Шафигуллина.

Ә менә аерып җыю гадәтенә кадәр әлегә ераграк икән. «Чүпнең дә бит капчыкка тутырылганы гына алына. Черек такта, бәрәңге сабагы, агач ботаклары һәм башкасы кала. Аларын кая куярга? Аерым контейнер чакыртырга мөмкин инде. Әмма аңа аерым түләү каралган һәм бу аз акча түгел», – ди Рамил.

Әңгәмәдәшебез тагын бер мәсьәләгә игътибар итте. «Шәһәр бәясе белән авылдагысы бер үк дип беләм. Шәһәрдә чүпне көн дә җыялар, ә бездә атнага бер. Калада махсус чүп контейнерлары һәм мәйданчыклары бар, ә авылда – юк. Авыл читтәрәк кала инде гел. Кимсетелә дияр идем. Ә чүп шәһәрдә дә, авылда да көн дә чыгып тора. Шушы җитешсезлек борчый», – ди ул.

– Берара ирем чүпне аерып җыярга маташты. Ләкин, гафу итегез, биш бала әнисе буларак, эштән арып кайткач, бер чиләк урынына өч чиләк чыгарасы килми икән ул. Гәрчә табигать хакына шулай кирәк һәм дөрес икәнен аңласам да. Ирем дә маташып карады, карады да ташлады инде, – ди Әлмәттә яшәүче Рәдифә Ногманова. – Хәзер Әлмәттә кәгазь, пластик һәм башка төр чүп-чарны аерым җыю өчен урыннар бар. Урамнан узганда, кулымда шундый чүп булса, билгеләнгән контейнерга салам. Кәгазь дигәнеңә – пластик, пластик салынырга тиешлесенә кәгазь салып киткәннәрен дә күргәнем бар. Әле кешене бу җәһәттән өйрәтәсе дә өйрәтәсе. Әмма Әлмәттә экологик яктан кызыксындыру чаралары еш була, максатчан эш алып барыла, дияр идем. Бездә чүпне «Гринта» дигән оешма җыя. Барысын бергә тапшырабыз, аерып җыю юк. Хәзер инде чүп өчен түләү нык кыйммәтләнде. Эшкәртүне дә исәпкә алдык, шуңа шулай кыйммәт дип аңлатканнар иде безгә.

Гаиләдәге экологик тәрбиягә килгәндә, Рәдифә ханым сүзләренчә, балалары үзләре белеп макулатура һәм пластик шешә капкачларын җыя башлаганнар.

Биектау районы Алан-Бәксәр авыл җирлегендә чүпне якшәмбе алып китәләр.

– Безнең җирлеккә биш авыл карый. «Чистый город» оешмасы башкара бу эшне. Машина кереп, пакеттагы чүп-чарны җыеп китә. Атна саен якшәмбе киләләр. Аена дүрт мәртәбә киләләр дигән сүз. Бер кешегә түләү бәясе – 108 сум 40 тиен, – дип аңлатты авыл җирлеге башлыгы Зөһрә Гарифуллина. – Аерып җыю культурасы юк әле. Бу кадәренә дә риза инде. Киләчәктә чүпләрне пакетка җыюдан туктап, контейнерларга күчәсе иде. Әлбәттә, моңа каршы кешеләр дә бар. Чөнки берәүнең дә йорты каршына чүплек куясы килми. Норма буларак, ул контейнер йортлардан 20 м ераклыкта урнашырга тиеш. Авылда андый җирне табу да кыенрак инде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

# САНЫ ДА, КАДЕРЕ ДӘ ЮК

**Бер көнне редакциягә Мамадыш районыннан Вахит абый шалтыратты. Сарык йонының капчык бәясеннән дә очсызрак йөрүенә күңеле әрни аның. «Әле шушы арада гына йон җыючылар кергән иде. Сатмадым, килосын нибары 5 сумнан алалар! Минем сезгә тапшырган йоным ул салынган капчыктан да очсызгарак чыга бит дип бирмәдем. Чүплеккә ташласам ташлыйм, әмма ул бәягә сатмыйм, дидем. Оятлары да юк: бер пар итекне кимендә бер мең сумнан санасаң да, күпме табыш керә бит! Ә йонны мыскыл итеп шундый бәягә җыялар», – ди ул. Хәзер сарык йоны нигә шулай түбән бәяләнә икән?**



pixabay.com

### Сүздә калган эш

Татарстанда сарык йоны, тиресен җыю бүген үзәкләштерелгән рәвештә алып барылмый. Бу эш белән, нигездә, берничә оешма белән алыпсатарлар гына шөгыльләнә. Дөрес, моннан берничә ел элек республикада сарык йонын җыю-сатуны системалы бер эшкә әйләндерергә тырышып карадылар үзе.

Хәтерләсәгез, моннан биш-алты ел чамасы элек Татарстанда сарык йоны, тиресен күпләп әзерләү эше торгызыла дигән хәбәр таралган иде. Бу җаваплы эш «Татпотребсоюз» идарәсенә тапшырылды. Оешма халыктан сарык йоны, тиресе җыюны үзәкләштерелгән рәвештә алып барырга тиеш иде. Аның кысасында халыктан ел саен 565 тонна сарык йоны һәм 150 мең берәмлек тире чималы җыеп булачак, дип ышандырдылар. Дәүләт тарафыннан бирелгән субсидияләр ярдәмендә белгечләр бу чималны халыктан җыю бәясен дә контрольдә тотарга өметләнде. Әмма бу вәгъдәләр сүздә генә калды.

Татарстан фермерлары һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеров моның берничә сәбәбен атый.

– Кызганыч, бу эш барып чыкмады. Билгеле булганча, Кукмарада данлыклы итек фабрикасы бар. Аларга бездәге чимал гына җитәрлек түгел. Ник дигәндә, бүген бездә сарык йоны тиешенчә җыелмый. Икенчедән, аларны халыктан сатып алу бәясе дә бик түбән. Ә йон һәрвакыт кирәк. Аннан итек кенә түгел, яхшы сыйфатлы юрган, мендәр, туннар да тегеп була бит. Хәзер Кукмара эшмәкәрләре белән зур эшкә алындык. Үзебезнең фермерлардан җыелган сарык йоны һәм тиресен үзебездә үк эшкәртеп, билгеле бер продукт ясау эшен җайга салырга җыенабыз. Юкса бүген әлеге төр чимал, нигездә, шәхси хуҗалыклардан гына җыела, – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

«Кукмара итек фабрикасы»ның тәэмин итү бүлеге белгече Марат Гарипов сүзләренә караганда, бүген биредә итек басу өчен йонны, дөрестән дә, чит төбәкләрдән, хәтта Казахстаннан ук кайтарталар. «Соңгы арада кертелгән чикләүләрнең тәэсирен сизмәдек. Бүгенгә безнең йон запасы бар. Дөрес, әлегә ул теләгәнчә үк җитәрлек күләмдә түгел. Йонны республикадагы аерым оешмалар, алыпсатарлардан да кабул итәбез. Кеше шәхсән үзе килеп тә тапшыра ала. Йонның килограммын 30 сумнан алабыз», – ди ул.

Бүген Татарстанда йон җыю белән ике зур оешма шөгыльләнә. Шуларның берсе – Кукмарадагы «ГАРО» тәэмин итү-сату авыл хуҗалыгы кооперативы, икенчесе – Казандагы «Татвойлок» оешмасы. Биредә сарык йонының килограммын 25–30 сумнан кабул итәләр. Үзләре үк итек җитештерү өчен тетелгән йон да саталар. Аның килограммын 140 сумнан озаталар.

### Тигәнәк хак төшерә

Азнакайның «Заготконтора» идарәсе җитәкчесе Тәнзилә Кәримова сүзләренә караганда, соңгы арада сарык йонының сыйфаты начарланган. Элек аны елына ике мәртәбә алсалар, хәзер бу эш бер тапкырга гына калган. Бу исә йонның сыйфаты начаррак булачак дигән сүз. «Хәзер басу тулы тигәнәк. Ә тигәнәкле йонны алмыйлар, алган очракта да ул бик арзан», – ди ул.

«Заготконтора» идарәсендә тигәнәккә баткан йонның килограммын күп дигәндә 12 сумга алалар икән. Көзге йонның килограммы 25 сумнан йөри. Ул иң сыйфатлы сарык йоны санала. Аннан итек басалар. Язгы йонны исә 15 сумнан кабул итәләр. Анысыннан биләй, урынҗир әзерлиләр. Идарә җитәкчесе сүзләренә караганда, сарык йонын алыпсатарлар да җыя. Аларда хаклар тагын да түбәнрәк.

– Без үзебез халыктан җыйган сарык йонын «Татвойлок» оешмасына 20 сумнан тапшырабыз. Әле ярый хөкүмәт тарафыннан бирелгән субсидия бар. Шул коткара. Оешмаларга тапшырыр алдыннан йонны эшкәртәбез, пресслыйбыз. Эшкәрткәндә аның бәясе бөтенләй төшеп бетә. Бүген йон җыю, эшкәртү отышлы эш түгел. Аңа сорау да зур түгел. Безнең заготконторада итек цехы бар иде. Хәзер бит кыш та җылы. Кайбер елны итек киярлек тә булмый, – ди Тәнзилә Кәримова.

«Заготконтора» идарәсеннән авылларга көн саен автолавка йөри икән. Авылга машина киләчәген алдан хәбәр итеп куялар да, халык билгеләнгән көнгә җыйган йонын әзерләп куя. Алып китүче булганда, бер-ике кило йонны сатсаң да, файда бит. Апрель аенда йөри башлаган йон җыю машинасы октябрьдә генә туктый икән. Аннары кирәк кеше идарәгә йонны үзе китерә.

Тәнзилә Кәримова әлеге тармакта 1980 нче еллардан бирле эшли. Ул елларны сагынып искә ала. «200әр тонна сарык йоны җыела иде. Аның хакы да югары булды. Хәзер аның күләме дә, бәясе дә юк. Халык мал санын да елдан-ел киметә бит. Сарык асраучылар да күп түгел. Шулай да йон җыю, эшкәртү эше юкка чыкмас ул. Мондый вазгыять озаграк сакланса, халык малын да, сарыгын да күпләп асрый башлаячак. Аларның йон хаклары да күтәрелер дип өметләнәм», – ди тәҗрибәле җитәкчесе.

Кулында җыелган сарык йоны булган кешеләргә исә аны юк кына бәядән алыпсатарларга биреп җибәрмәскә киңәш итә ул. Мөмкинлек булса, аны бу эш белән шөгыльләнгән махсус оешмаларга илтеп тапшыру хәерлерәк, ди Тәнзилә Кәримова.

Әлки районында сарык йоны җыю белән шөгыльләнүче алыпсатар Алмаз Галимҗанов исә бу фикер белән килешми. Алыпсатарлар да йонга уртача хак куярга тырыша, ди ул. Халыктан сарык йонын җыеп тапшыру – Галимҗановлар нәселенең күптәнге кәсебе. Әтисенең юлын дәвам иткән Алмаз үзе бу эш белән егерме елдан артык шөгыльләнә икән.

– Әти эшләгән чорда йон саткан акча белән салым түләп булган. Хәзер сарык йонының бәясе чыгымнарны да акламый. Бүген халык малны да азрак асрый. Асраганы да сарык йонын яндыра яисә җиргә күмеп котыла. Мин үзем сарык йонының килосын 15 сумнан җыям. Сыйфатлысына да, сыйфатсызына да – шул бер бәя. Йонны күрше-тирә районнардан гына түгел, Ульяновскидан да җыям, – ди ул.

### Йоны түгел, ите

Югары Ослан районының Түбән Ослан авылында яшәүче фермер Илшат Садриев хуҗалыгында бүген 400 башлап сарык исәпләнә. Аларны ит өчен генә асрыйм, ди ул. Ник дигәндә, бүген сарыкның йоны да, тиресе дә файда китерми.

– Совет чорында сарыкның йоны итеннән ике тапкыр кыйммәтрәк йөри иде. Элек сарыкны ит өчен түгел, йон өчен асраганнар. Сарыкның йоны – 8 сум, ите 4 сум торган. Бүген киресенчә. Сарык йоны безнең өчен артык мәшәкать кенә булып тора. Аның йоны түгел, тиресенең дә кирәге юк. Шәхсән без анысын ташлап барабыз. Аларны ит өчен үрчетәбез. Аның килосы бүген 400 сумнан да ким йөрми. Совет чорында сарык йонына сорау да зур иде. Аннан нәрсә генә җитештермәделәр. Хәзер бит бар әйбер синтепоннан эшләнә. Бүген тун кигән кеше дә сирәк, – дип сөйләде ул.

Алыпсатарлар Илшат абыйның ишеген дә каккан. Сарык йонын 10 сумга сатып алмакчы булган алар. Әмма фермер мондый юк бәягә риза түгел. Сарык йонын җыеп барып, килограммын 30 сумнан Кукмарага илтеп тапшыра икән.

– Ставропольдә яхшы сарык йонының килограммы 500 сумнан йөри. Бездә бу эш җайга салынмаган шул. Сарык йонын сатудан да тиеннәр генә керә. Бер сарыкның йонын алган өчен 150 сум акча түлим. Бер баштан 2–3 кило йон чыга. Шуны 30 сумнан сатсаң да аның нинди файдасы калсын?! Соңгы арада безнең якта яңа токымлы сарыклар үрчетә башладылар. Аларның йоннарын да аласы юк, кәҗәнеке кебек үзләре коелып бара, – ди фермер.



Сүз уңаеннан, бүген республикада күпләп мөгезле эре терлек тиресе дә җыела. «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән тире җыючылар сүзләренә караганда, хәзерге вакытта үгез тиресенең килосы – 30 сумнан, тананыкы 10 сумнан йөри. Сугым чорында үгез тиресенең хакы – 45 сумга, тананыкы 25 сумга кадәр күтәреләчәк, дип фаразлый алар.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

## 26 сентябрь | Дүшәмбе

**ТАТАРСТАН**

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

**ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР**

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2» 12+
10.00, 23.30 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века» 12+
19.00, 20.00, 00.45 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Каравай». Азербайджанские ковры 6+
01.40 «Ватандашлар» 12+
02.05 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+

**ТНВ-ПЛАНЕТА**

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башкаткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05, 18.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Әхәт Гаффар турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.15, 21.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «Татар теле дәресләре» 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+

**1 КАНАЛ**

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 В честь 350-летия Петра Великого. Премьера. Большое кино: «СОБОР» (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

**РОССИЯ 1**

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Равшана Куркова, Юрий Чурсин, Николай Добрынин, Юлия Галкина, Юлия Мельникова, Илья Любимов. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+
02.50 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР!-2» 16+

**МАТЧ ТВ**

06.00, 08.55, 12.30 Новости
06.05, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.00, 12.35, 04.50 Специальный репортаж 12+
09.20 «САМОВОЛКА» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 Регби. PARI Чемпионат России. «Красный Яр» (Красноярск) – «Слава» (Москва). Прямая трансляция
14.55 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Спортивная гимнастика. Командное многоборье. Мужчины. Прямая трансляция из Казани
18.30 «Громко». Прямой эфир
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
22.30 Тотальный футбол 12+
23.00 «РАЗБОРКИ В СТИЛЕ КУНГ-ФУ» 16+
01.00 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Спортивная гимнастика. Командное многоборье. Мужчины. Трансляция из Казани 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «ФАНТОМ» 12+
05.05 «Громко» 12+

**НТВ**

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
21.45 Премьера. Детективный сериал «СТАЯ» (S) 16+
00.00 Детективный сериал «БАЛАБОЛ» (S) 16+
01.55 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

**ДОМАШНИЙ**

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Я тебя поймала» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «СТАРУШКИ В БЕГАХ». 1-я – 4-я серии 16+
19.00 «ПЕРВОКУРСНИЦА» 16+
22.45 «Порча». «Крик» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.50 «Тест на отцовство» 16+
03.30 «Давай разведёмся!» 16+
04.20 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

**ЗВЕЗДА**

05.05 «ИНКАССАТОРЫ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «БИТВА ЗА МОСКВУ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БРАТСТВО ДЕСАНТА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Единые пулемёты. Пулемет Калашникова против М60». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Хайнц Мюллер. Немец, который брал Берлин» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «КОРПУС ГЕНЕРАЛА ШУБНИКОВА» 12+
01.15 «ВОРОТА В НЕБО» 12+
02.40 «Легендарные самолеты. Истребитель Ла-5». Док. фильм 16+
03.25 «БРАТСТВО ДЕСАНТА» 16+

## 27 сентябрь | Сишәмбе

**ТАТАРСТАН**

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

**ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР**

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 15.15 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2» 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА – ТОВАРИЩИ» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «ОФИЦЕР ХАТЫННАРЫ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Казаннан – казанга» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Надежда Дурова, или Штаб-ротмистр Александров из Елабуги 12+
00.45 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.10 «Татар әдәбияты дәресләре» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

**ТНВ-ПЛАНЕТА**

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Кызыклык әле!» 6+
09.40 «Родная земля» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20 «Кискен җилгә ак җилкән». Фирая Әкбәрова турында телеочерк 6+
19.15, 21.25, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
22.20 «Татар теле дәресләре» 6+

**1 КАНАЛ**

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. Большое кино: «СОБОР» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

**РОССИЯ 1**

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Михаил Пореченков, Александра Богданова, Юлия Мельникова, Илья Любимов. «ЧАЙКИ» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 16+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!-2» 16+

**МАТЧ ТВ**

06.00, 08.30, 13.30 Новости
06.05, 15.30, 19.15, 21.45 Все на Матч! Прямой эфир
08.35 Летний биатлон. Pari Чемпионат России. Индивидуальная гонка. Мужчины. Прямая трансляция
10.40 «Есть тема!» Прямой эфир
11.45 Летний биатлон. Pari Чемпионат России. Индивидуальная гонка. Женщины. Прямая трансляция
13.35 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Спортивная гимнастика. Командное многоборье. Женщины. Прямая трансляция из Казани
16.00 Смешанные единоборства. Eagle FC. Александр Шлеменко против Артура Гусейнова. Трансляция из Сочи 16+
16.55 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
19.25 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Москва) – «Авангард» (Омск). Прямая трансляция
22.30 «БЕЗЖАЛОСТНЫЙ». Художественный фильм 16+
01.00 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Спортивная гимнастика. Командное многоборье. Женщины. Трансляция из Казани 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «ФАНТОМ» 12+
04.50 Специальный репортаж 12+
05.05 «Человек из футбола» 12+
05.30 «Главная команда» 12+

**НТВ**

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Остросюжетный сериал «ЛИХАЧ» (S) 16+
21.45 Премьера. Детективный сериал «СТАЯ» (S) 16+
00.00 «БАЛАБОЛ» (S) 16+
01.50 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» (S) 16+

**ДОМАШНИЙ**

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Проклятый клад» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «СТАРУШКИ В БЕГАХ». 5-я – 8-я серии 16+
19.00 «КАК МЫ ЛЮБИЛИ ДРУГ ДРУГА» 16+
23.00 «Порча». «Орудие убийства» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.05 «Тест на отцовство» 16+
03.45 «Давай разведёмся!» 16+
04.35 «ЖЕНСКАЯ КОНСУЛЬТАЦИЯ» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

**ЗВЕЗДА**

05.55 «БРАТСТВО ДЕСАНТА» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20 «БИТВА ЗА МОСКВУ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «БРАТСТВО ДЕСАНТА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Битва оружейников». Док. сериал. «Реактивные системы залпового огня. БМ-21 против LARS, MLRS и LAR». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «КОМАНДИР КОРАБЛЯ» 12+
01.30 «ЕДИНСТВЕННАЯ...» 12+
03.05 «ВДВ: жизнь десантника». Док. фильм 12+
03.30 «БРАТСТВО ДЕСАНТА» 16+

# ЙОЛДЫЗНАМӘ 26 СЕНТЯБРЬ – 2 ОКТЯБРЬ

**КУЧКАР (21.03 – 20.04)**
Бу атнада игътибар үзәгендә калырсыз. Әмма сезгә сокланулы карашларның төбәлүен генә аңлатмый бу. Кимчелекләрегез дә күренәчәк. Чәршәмбе тирәсендә бурычларыгыздан котылырсыз.

**ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)**
Эчке сиземләвегез тормышыгызны яхшы якка үзгәртү мөмкинлеге бирәчәк. Җитәкчегез башкарган эшегезнең нәтиҗәсен күреп, үзегезне мактап туя алмаячак. Шулай итеп, мөнәсәбәтләрегезгә дә җылылык өреләчәк.

**ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)**
Барысын да яңадан башлагыз һәм беркайчан да үзегезне сукмәгез. Бу атнада сезгә әнә шушы киңәшләр ярап куярга мөмкин. «Юк» дисәләр дә, чигенмәгез. Шулай гына уңышка ирешәчәксез.

**КЫСЛА (22.06 – 22.07)**
Ашыкмаска, билгеле бер кагыйдәләрдән чыкмаска, эчке хис-тойгыларны тыярга! Шулай икән, эшләрегез гөрләп барачак, керемнәрегез артачак. Ял көннәрендә дулкынланырга мәҗбүр итәрләр. Әмма күңелле дулкынлану булачак бу.

**АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)**
Күптәнге бер проблемагыз көтмәгәндә генә искиткеч дәрәҗәдә җиңел хәл ителеп куяр. Тыйнак һәм җыйнак булуыгыз нәтиҗәсендә әйбәт кенә уңышка ирешерсез. Уйламаган җирдән гаиләгездә сөенечле хәлләр килеп чыгар.

**КЫЗ (24.08 – 22.09)**
Теге яки бу карарга ничек тизрәк килсәгез, шуның кадәр яхшырак. Юкса урыныгызны башка кеше алачак. Атна ахырында әйбәт хәбәрләр ишетеләчәк.

**ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)**
Агым уңаена йөзү чоры түгел. Җиңү хисен тою өчен эшләп тә күрсәтергә кирәк булачак. Кемнәргәдер яраклаша алмаячаксыз, аның каравы тирәгездәге иң ышанычлы кешеләрнең кемнәр икәнен аңлаячаксыз.

**ЧАЯН (24.10 – 22.11)**
Бу атнада күптәнге планнарыгызны тормышка ашырып, яңа биеклеккә чыгарсыз. Сезне хезмәт баскычыннан югарыга күтәрелү, яңа вазыйфа, саллы керем көтә. Әмма кыю гамәлләргә керешкәнче, «плюс» һәм «минус»ларын яхшылап уйлагыз.

**УКЧЫ (23.11 – 21.12)**
Атна башында киеренке эш байтак кына көчегезне суырыр. Ләкин офыкта яхшы гына суммаларның шәйләнүе бөтен ару-талуыгызны онытырыр. Шәхси проблемагызны хәл итү өчен эчкерсез сөйләшү дә җитәр.

**КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)**
Катлаулырак хәлләр чыгарга мөмкин. Бик көчле хис-тойгылар өермәсендә калуыгыз бар. Әйткән сүзләрегез өчен җавап бирергә, үзегезгә йөкләнгән бурычларны үтәргә әзер булыгыз. Иң мөһиме – сабырлык.

**СУКОЯР (21.01 – 19.02)**
Әллә кайчаннан бирле сөйләп килгән эшләрегезне төгәлләргә, фикерләрегезне тәртипкә салып, алдыгызга төгәл генә максат куярга туры килер. Атна уртасында барысы да яхшыга таба үзгәрер, җитәкчегез эшегезне югары бәяләр. Хезмәттәшегез әйбәт кенә яңалык белән куандырыр.

**БАЛЫК (20.02 – 20.03)**
Эштә саграк булыгыз, вәгъдәләргә ышанмагыз. Гаилә бюджетыннан бәрәкәтлерәк файдалану турында уйланырга сәбәп чыгар. Ял көннәрендә бер дустыгыздан әйбәт кенә яңалыклар ишетелер.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

**2022 елда Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү турында**

Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимен караганнан соң **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасының М.И. Мәхмүтов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә бирергә:

Мөсәлимова Әлфия Рафис кызына – педагогика фәннәре докторы, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Психология һәм белем бирү институтының югары мәктәп педагогикасы кафедрасы мөдиренә;

Скобельцына Елена Германовнага – педагогика фәннәре кандидаты, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф югары белем бирү учреждениесенең «Н.И. Лобачевский исемендәге лицей» гомуми белем бирү мәктәп-интернаты директорына.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 21 сентябрь
№ ПУ-653

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

# ӘЙТЕП КЕНӘ БЕТМИ

**Арпа дисәң – арта, бодай дисәң – бетә. Им-томга ышанучылар күзгә чыккан арпадан әнә шулай котылырга киңәш итә. Табиблар исә аны белгеч кушкан алымнар белән дәваласаң да таманга килә, дип кисәтә. Күзгә арпа чыгуга җитди карарга өнди алар. Ник дигәндә, вакытында һәм дөрес итеп дәваламасаң, ул җитди авыруга ук әверелергә мөмкин.**

**Республика офтальмология хастаханәсе табиб-офтальмологы Элина МИНХУҖИНА күзгә чыккан арпаның без белмәгән яклары турында сөйләде.**

**:: Элина Ленаровна, күзгә арпа чыгу бигрәк тә нәрсәсе белән куркыныч?**

– Халык телендә күзгә арпа чыгу дип йөртелгән күренеш фәнни телдә гордеолум дип атала. Ул керфек төбендәге май бизләре яки төк янчыгының эренләп шешүеннән гыйбарәт. Тышкы кыяфәте белән арпаны хәтерләткәнгә күрә аңа шундый исем бирелгән дә инде. Теләсә кайсы ялкынсынулы күз авыруы куркыныч. Шуңа күрә күзгә арпа чыгуга да бармак аша карарга ярамый. Аны үз белдегеңнән белән дәваларга маташу да – зур хата. Кайберәүләр хәтта күзгә чыккан арпаны сытарга ук керешә. Янәсе, болай эшләгәндә ул тизрәк төзәләчәк. Әмма аны сыткан очракта күз чокыры һәм күз кабагы үлекләргә, андагы кан агуланырга мөмкин.

**:: Ул ни сәбәпле пәйда була?**

– Күздәге арпаны, нигездә, стафилококк дигән бактерияләр китереп чыгара. Алар кешенең тәнендә, чәчләрендә очрый. Иммунитет нык булганда, организм аларга бирешми. Иммунитет какшауга, алар да активлаша. Стафилококклар үтеп кергәч, чәч тамырларында ялкынсыну башлана. Керфек төбендәге арпа да шул рәвешле пәйда була. Дөрес тукланмаган, чамадан тыш авыр физик эш башкарган, даими рәвештә стресс кичергән кешедә ул берничә урында ук чыгарга мөмкин. Пычрак куллар белән күзне уу, тузанлы бүлмәдә утырган очракта да күзгә арпа чыгарга мөмкин. Эндокрин, ашказаны-эчәк системасы авырулары булган, урамда яки санитария таләпләре үтәлмәгән җирдә эшләүче яки ялкынсынулы күз авырулары кичергән һәм ахыргача дәваланып бетмәгән кешеләрдә гадәти күренешкә әверелә ул.

**:: Сыйфатсыз косметика куллану аркасында да күзгә арпа чыга аламы?**

– Теләсә кайсы косметиканы, әйтик, шул ук тушьны кулланганда без тән тиресе, күз һәм күз кабакларының саклагыч катламын зарарлыйбыз. Шул рәвешле күзгә төрле ят кисәкчекләр, инфекция үтеп керү өчен менә дигән шартлар туа. Күз кабагына косметика тидергәндә без тире бизләренең чыгу юлын томалыйбыз. Бу исә үз чиратында күзләрне ярсыта. Нәтиҗәдә күз кабаклары чите (блефарит), күз кабагы кимерчәге ялкынсынуга (халязион) китерергә мөмкин. Дөрес, арпаның кайсы төр косметика кулланганч килеп чыкканын фәнни яктан раслаган мәгълүматлар юк. Әмма шунысы хак: теләсә кайсы косметиканы дөрес кулланмаган, көн азагында аны дөрес бетермәгән очракта, күздә гордеолум пәйда булу куркынычы бермә-бер арта.

**:: Күзгә чыккан арпадан ничек котылырга?**

– Иммунитет нык булган очракта, күздәге арпа бернинди дәвалаусыз, үзеннән-үзе дә бетәргә мөмкин. Аны өйдә үзлегеңнән генә дәваларга киңәш ителми. Бу очракта еш кулланылган халык медицинасы чаралары да билгеле. Шәхсән аларны хупламыйм, әмма аларга каршы да килмим. Әмма бу очракта шунысын истә тотарга кирәк: күзгә чыккан арпаны алар нигезендә дәвалаган очракта күздәге үлекле шеш тишелергә, шуның аркасында күзгә инфекция эләгеп, иң аянычлы нәтиҗәләр күзәтелергә мөмкин. Шуңа күрә гордеолум табиб күзәтүе астында дәваланырга тиеш. Белгеч бу очракта бактерияләргә каршы чаралар кулланачак.

**:: Күзгә чыккан арпа коронавирустан өзлегү дә була аламы?**

– Коронавирусның күзләргә дә зыян салуы фәнни дәлилләнгән. Әмма күзнең лайлалы тышчасы конъюнктивит, блефароконъюнктивит кебек күз авырулары аркасында зарарланырга мөмкин. Шуңа күрә коронавирус күз авыруларының баш калкытуына китерә дисәк дөресрәк булыр. Коронавирус белән авырып терелгәннән соң иммунитет какшау, күз кабакларында хроник үзгәрешләр пәйда булу аркасында күзгә арпа чыгу өчен җирлек пәйда булырга мөмкин. Әмма бу коронавирустан соң өзлегүнең бер төре дигән сүз түгел.

pinterest.com

### КҮЗГӘ АРПА ЧЫКМАСЫН ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

✓Еш кына безгә бер үк күзгә даими рәвештә арпа чыгудан зарланып мөрәҗәгать итәләр. Бу очракта кеше үзенең, нигездә, нинди чирдән интегүенә игътибар итәргә кирәк. Ашказаны-эчәк тракты авырулары, шикәр чиреннән интегүчеләр еш кына күзгә арпа чыгудан тилмерә.
✓Аны кисәтү өчен, иң беренче чиратта, гигиена кагыйдәләрен төгәл үтәргә, иммунитетны ныгытырга кирәк.
✓Тәннең артык җылынуы яки туңуыннан да сакланырга кирәк.
✓Инфекцияле, җитди авыруларны да вакытында дәваларга кирәк.
✓Актив тормыш рәвеше алып бару, дөрес туклану да күзгә арпа чыгуны кисәтергә ярдәм итәчәк.
✓Күзгә арпа чыкканда мунчада, саунада парланып утырырга ярамый.
✓Күздәге арпа еш кына җитдирәк авыруга (халязион) әверелә. Андый чакта күзнең кимерчәк тукымасы ялкынсынып, анда тыгыз шарчык пәйда булырга мөмкин. Бу очракта аннан операция ярдәмендә генә котылып була.

# МАЙНЫҢ МЕҢ ШИФАСЫ

**Зәйтүн мае.** Бу майны кулланганда аның әчелегенә игътибар итәргә кирәк. Ул шешәнең этикеткасына язылган була. Май никадәр әче булса, аның сыйфаты шулкадәр түбәнрәк (0,8 проценттан артмаска тиеш). Зәйтүн мае кан тамырларын чистарту үзлегенә ия. Башка майлардан аермалы буларак, кыздырганда канцерогеннар бүленеп чыкмый.

**Кабак мае**нда цинк күп. Тестостерон гормоны барлыкка килсен өчен цинк булган ризыклар ашарга куша белгечләр, димәк, ул ир-атларга бик файдалы. Иммунитетны күтәрә, вируслы авыруларга каршы торучанлыкны арттыра торган селен матдәсе дә бар кабак маенда. Салатлар өчен яхшы, ләкин кыздырырга ярамый.

**Кукуруз мае** организмда холестеринны җайга сала. Баш мие эшчәнлеге өчен файдалы, анда йөрәк эшчәнлеге өчен кирәк булган PP витамины бар.

**Горчич мае**нда A, D, E, K, B группасы витаминнары бар. Май микробларны юкка чыгару сәләтенә ия, салатларга кушарга була. Горчичнең төренә карап, маенда кеше организмында таркалмый, ә күзәнәкләрдә җыела торган кислотаның чамадан тыш күп булганнары да очрый. Шуңа да аны артык күп кулланырга киңәш ителми. Җылыту сәләтенә ия булганга, тәнне ышкырга, массаж ясаганда кулланырга була.

**Киндер мае** иң түбән калорияле май булып санала. Организмны чистарта, чирләргә каршы торучанлыкны арттыра, бавыр эшчәнлеген яхшырта, гастриттан, эч катудан, әче килүдән дәва, суалчаннарны чыгара. Омега-3 һәм Омега-6 май кислоталары балыктагыга караганда да күбрәк. F, A, E, B, K витаминнары, яшелчә, җиләк-җимештәге нитратларны юкка чыгара торган тиопронин антиоксиданты бар. Әлбәттә, салатлар өчен дә бик тәмле.

**Көнҗет мае**нда кальций күп. Көмәнле вакытта, гормоннар эшчәнлеге бозылганда эчү файдалы. Организмнан тозларны чыгара, калкансыман биз авыруларына дәва. Кан оючанлыгын арттырганга, йөрәк һәм кан тамырлары авырулары булган кешеләргә куллану киңәш ителми.

### Белә идегезме?

### Буынга да шифалы

Алманың организм өчен ни дәрәҗәдә файдалы икәнен һәркем белә. Баксаң, алманы авырткан буыннарга сылап та шифасын күрергә була икән бит. Моның өчен алмаларны кыргычтан үткәрегез дә, киҗе-мамык тукымага калын итеп сылап, авырткан буыннарыгызга куегыз. Аның өстеннән – полиэтилен, аннан мамык шәл урагыз. Бу эшне йоклар алдыннан башкарырга кирәк. Алмалы шәлне тәүлек әйләнәсе тотсаң да зыян итми.

### Иттән баш тарту хәерле

Йөрәк, инсульт һәм яман шеш авыруларын кисәтим дисәң, иттән баш тарт! Эдинбург галимнәре шулай дип ышандыра. Алар туклану рационында яшелчә һәм җиләк-җимеш күләмен арттырырга, ә ит ашауны киметергә тәкъдим итә. «Болай эшләгәндә кешеләрне авыр чирләрдән саклап, коронавирусның авыр нәтиҗәләрен булдырмыйча калырга мөмкин», – ди алар. Бу очракта 2060 елга кадәр ел саен 26 миллион кешене үлемнән саклап калып булыр иде дип исәпләп чыгарган алар.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА

# Тәнне дә, җанны да дәвалый

**Сәламәтлеге какшап киткәннән соң виноград үстерүгә керешкән Леонтий Кирягин хакында Татарстанда гына түгел, бөтен Россиядә беләләр. Ашказаны җәрәхәте белән пычак астына керүдән аны нәкъ менә әлеге җимеш саклап калган. 87 яшендә дә әле егетләрдәй җәһәт, тиктормас Леонтий КИРЯГИН Казанның Дәрвишләр бистәсендәге дистә сутыйга якын бакчасында виноградның 60ка якын төрен үстерә. Тәненә дәва тапкан виноградчы, аны үстерү җанны да дәвалый, ди. Ул виноград үстерүчеләрне борчыган сорауларга җавап бирде.**

**:: Леонтий Иванович, быел күп кенә бакчачылар, виноград өлгермәде, дип зарлана. Бу нилектән шулай?**

– Виноград – җылы һәм кояш ярата торган культура. Ул чәчәк атканда һава торышының бик яхшы булуы шарт. Виноградның уңуына май һавасы сәбәпче. Ә быел май салкын һәм дымлы булды. Бу вегетация чоры тоткарланудан тыш кайбер авыруларның азуына да сәбәпче булды. Виноград гадәттә июнь башларында чәчәк ата иде, ә быел бер айга соңарды. Бу бездә генә түгел, бөтен Россиядә шулай. Мин башка төбәкләрдә яшәүче виноградчылар белән элемтәдә торам, аларда да шундый ук зар. Дөрес, июль белән август җылы булды, тик виноград өлгерү өчен ике ай гына вакыт җитми. Бөтен өмет сентябрьдә булачак әбиләр чуагында иде, анысы да әллә ни куанырлык булмады. Виноград өлгерми калды, ул бит шикәр туплаганнан соң гына өлгергән дип санала.

**:: Климат үзгәргән саен, виноград үстерү технологиясе дә үзгәреп тора, димәк. Бездә виноградның нинди сортларын утыртырга киңәш итәр идегез?**

– Әйе, климат белән бергә аны үстерү технологиясе дә үзгәрә. Шунлыктан виноград үсентесе сайлаганда сортка игътибар итәргә кирәк. Виноградның безнең полосага ультра иртә, иртә һәм уртача иртә өлгерә торган сортлары туры килә. Теләгең булса, озаграк өлгерә торган сортларны җылытылмый торган теплицаларда үстерергә була. Уртача тәүлеклек температура +10 градус булганда виноградның вегетация чоры башлана. Теплица виноград өчен җәйне «озайта», шуңа күрә ачык грунтта өлгерми торган сортлар анда рәхәтләнеп үсәчәк.

**:: Виноград утыртырга ниятләүчеләргә үсентене кайдан алырга киңәш итәр идегез?**

– Аны базардан үтеп барышлый теләсә нинди сатучыдан алганчы, виноград үстерүчедән алуың хәерле. Мәсәлән, мин үземнән алучыларга утырту, тәрбияләү турында бөтен мәгълүматны сөйлим, аннары да элемтәдә торам. Минем виноград үстерү буенча «укучы»ларымның саны бихисап. Алар җимеш өлгергән чорда килеп авыз итеп карап, үзләренә туры килгәнен дә сайлый алалар. Виноград үсентесен сайлаганда шул килеш ашау, киптерү, шәраб ясау өчен кирәк булуын тәгаен белеп сайларга кирәк.

**:: Сезнең үзегез чыгарган виноград сортларыгыз бармы?**

– Сортлар түгел, гибрид формалар гына. Гибрид формалар дәүләт реестрына кертелмәсә, ул сорт булып танылмый. Гибрид формаларны чыгару өчен шактый җир һәм кимендә 10–15 ел запас вакыт кирәк. Ә минем аның кадәр вакытым калмады.

Автор фотосы

**:: Виноградны көздән утыртып калдыруың яхшымы, әллә язга калса да ярыймы?**

– Моңа кадәр виноград утыртканыгыз булмаса, әлеге эшне язга калдырсагыз яхшырак булыр. Чөнки аның үсешен карап, күзәтеп торырга була, ә көзен каплап куйганнан соң виноградның ничек кыш чыгасын тәҗрибәле виноградчыга да чамалау кыен.

**:: Виноградны капламыйча гына кышлатырга ярыймы?**

– Капламый калдырырга ярамый. Мин тактадан махсус әрҗә ясыйм да, куакларны төреп, шуның өстенә салам. Аннары өстен яңгыр үткәрми торган материал белән каплыйм. Виноградны бик иртә капламавың хәерле. Чөнки көз озын килеп, көннәр җылытып җибәрсә, бөреләре уяныш, зыян килергә мөмкин. Октябрь ахыры, ноябрь башы – иң кулай вакыт. Беренче салкыннарда чыныгып калса, кыш чыгу өчен яхшырак булачак. Виноград – бик «акыллы» үл. Салкыннар якынаюга аның сабаклары яшеллеген җуеп, сорырак төскә керә башлый.

**:: Виноградны карлыган шикелле очын кисеп алып кына үрчетеп буламы?**

– Була, тик бу карлыган төсле һәркемнең кулыннан килә торган эш түгел. Тәҗрибәсе булмаганнарга үсентене сатып алырга киңәш итәм. Чыбыкчадан виноград үстерү өчен махсус шартлар һәм хәйран вакыт таләп ителә. Ул утыртканнан соң өченче елны гына уңыш бирергә мөмкин.

Укучы киңәше

## Чикләвек озак саклансын

Быел безнең якта чикләвек уңды. 1980 нче еллардагы төсле үк булмаса да, авыз итәрлек тә, кыш сакларлык та булды. Чикләвекнең төше тәмсезләнмәсен дисәгез, аны кәшәнкәсеннән аергач, берәр атна коры урынга җәеп җиллətегез. Чистартканда кортлыларын калдырырга тырышмагыз, чөнки чикләвек корты башкаларына да кереп чыгарга күп сорамас. Аннары духовкада киптереп алырга кирәк. Мин үзем газ мичен 120 градуска кадәр җылытып, аны бераз ачык калдырып, 4–5 сәгать тотам. Болай иткәндә чикләвек тәмле була һәм озак саклана. Шулай ук махсус киптерә торган җайланмаларда да киптерергә була. Аннары чүпрәк яки кечкенә киндер капчыкларга тутырып куйсаң яхшы. Пакетта сакламаска тырышыгыз.

Гүзәл ХӘЙДӘРШИНА. Мамадыш

Лайфхак

### Бер елда – 60 мең!

Сез акча җыя беләсезме? Белмəсәгез, бер җайлы гына ысулы бар. Моның өчен ел буе көн саен 166 сум акчаны банкага яки копилкага салып барыгыз. Ә бер елдан сезнең анда 60 мең сумнан артык акча җыелачак!

# Гөмбә булмаса, күркә бар

**Социаль челтәрләрдә күп итеп күркә җыйган Тәнзилә Гыйлемханова фотосын күргәч: «Моны нишләтәсез?» – дигән сорау бирми кала алмадык.**

– Булса, урыны күп аның. Гөмбә булмаса, күркә дә ярый, – дип шаярта Тәнзилә.

**Самавыр кайнату өчен.** Ирем аны самавыр кайнатканда куллана. Әлбәттә, аны төп ягулык итеп кулланып булмый, чөнки ул тиз янып бетә, шунлыктан аны соңрак өстәргә кирәк. Аны салып кайнатылган чәйнең үзенә бер хуш исе була.

**Мулчәләү өчен.** Роза һәм ылысла агач төпләрен мулчәләү өчен кулланырга мөмкин. Ул дым сакларга ярдәм итә, туфракның көпшәкләнеп саклый, чүп үләннәрдән коткара. Кайберәүләр аны сукмак буйларына җәяләр, бакчаны бизәү өчен кулланалар. Мин дә күркәләрне яңа розаларым төпләренә җәяргә торам.

**Төрле әйберләр ясау өчен.** Мәктәп һәм балалар бакчаларында көзге уңыш бәйрәмнәренә әйберләр ясау, Яңа ел уенчыклары итеп куллану өчен дә бара.

Тәмле булсын!

## Миләүшә Якуповадан киптерелгән помидор рецепты

Уртача зурлыктагы яки ваграк помидорларны бөҗралап турарга һәм майланган фольга өстенә тезеп чыгарга. Помидорның өстенә генә төшәрлек итеп, тоз сибәргә. Аннары алдан 90–100 градуска кадәр җылытылган мичкә тыгарга. Помидорлар «тартыла» башлаганчы мич ишеген бераз гына ачып пешерергә. Мичтән алып, өстенә кабат бераз тоз, тәмләткечләр (нинди булса да ярый, мин кипкән базилик белән кара борыч сиптем), май салып, кабат мичкә тыгарга. Аның кипкәнлеге шундук аңлашыла. Киптерү өчен 4–6 сәгать вакыт кирәк. Аннары алып, стерильләштерелгән банкаларга тутырып суыткычка куярга.

pinterest.com

# ҮПКӘ КҮПКӘ КИТМӘСЕН

**Тел сөяксез, ди халык. Кайчак шушы телебез белән якыннарыбызны рәнҗетергә, үпкәләтергә мөмкин без. Хәтта урынсыз шаяруың белән дә кешенең күңеленә тиюең бар. Ул моны уенга борып, җиңел генә уткәреп җибәрсә ярый ла. Әмма арабызда юк кына сүзгә үртәлеп, еллар буе үпкә саклап йөрүчеләр дә шактый. Үпкә саклау нәрсәсе белән куркыныч? Гафу сорап килгән кешене кичермәү гөнаһмы?**

**«Тәүбә» мәчетеннән Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән шул сорауга җавап эзлибез.**

– Үпкәләү – йөрәкне бетерә торган рухи авыру. Чир организмны ничек зарарласа, шушы рухи авырулар да аңа шулай ук зыян сала. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Мөселман кешесе ул шундый кеше, кемнән башка кешеләр теленнән дә, кулыннан да зыян күрми», – дигән. Икенче бер хәдистә: «Кеше игътибар бирмичә, уйламыйча, бер сүз әйтә һәм шул сүз өчен җитмеш елга җәһәннәмгә әләгә», – диелә. Шул рәвешле уйламыйча әйткән сүз үпкә тууның бер сәбәбе булып тора. Пәйгамбәребезнең тагын бер хәдисеннән аңлашылганча, Кыямәт көнендә берсе икенчесенә карата гаделсезлек кылган ике кешене бастырачаклар да хөкем чыгарачаклар. Гаделсезлек кылган кешенең савапларын алып, аны үпкәләтелгән кешегә бирәчәкләр. Рәнҗетелгән кешенең гөнаһлары исә үпкәләтүчегә биреләчәк.

**:: Өч көннән артык үпкә саклау – гөнаһ, диләр. Бу дөрестән дә шулаймы?**

– Әйе, бу дөрестән дә шулай. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Мөселман кешесенә өч көннән артык үпкә саклау, сөйләшмәү тыела. Иң беренче булып сәлам биргәне – иң хәерлесе», – ди. Икенче бер хәдистә: «Кем дә кем үпкә саклап, мөселман кешесе белән өч көннән артык сөйләшми йөри, шул утка керә», – ди. Шуңа күрә бу пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең боерыгы булып тора. Ул безнең өчен кагыйдә булырга тиеш. Шуңа күрә хәтта шаярган очракта да сүзеңне үлчәп әйтергә кирәк.

**:: Кеше исән чакта аннан гафу үтенергә өлгермәсәң, ни эшләргә?**

– Кешене үпкәләтүеңне аңлауга ук, аның янына барып, гафу үтенергә кирәк. Пәйгамбәребез дә: «Йә хәерлесен сөйлә, йә бөтенләй сөйләмә», – дигән. Мондый кыен хәлдә калмас өчен иң беренче чиратта телеңә игътибар итәргә кирәк. Пәйгамбәребез дә аз сүзле булган. Беркайчан да артыгын сөйләмәгән, кешеләрдән көлмәгән, аларны кыерсытмаган, артыгы белән шаярмаган. Ник дигәндә, тел аркасында кешенең җәһәннәмгә үк барып керергә мөмкин икәнен бик яхшы аңлаган.

**:: Үпкәчел, үпкә саклап яши торган кешеләр яман чирләргә ешрак бирешә, ди галимнәр. Дини яктан карасак, үпкә саклау белән чиргә бирешү-бирешмәү арасында бәйләнеш бармы?**

– Әйткәнемчә, үпкәләү ул – йөрәкне зарарлый торган рухи авыру. Без тәнебезне, әгъзаларыбызны физиологик кына түгел, рухи яктан да сәламәт килеш тотарга тиеш. Әйтик, йөрәгеңдә көнләшү бар икән, бу үз-үзеңне ашау, бетерүгә генә китерә. Моңа йөрәк тә чыдамый, билгеле. Үпкә саклау да йөрәкне бик нык таушата. Инфарктлар да, нигездә, әнә шул сәбәпле килеп чыга.

**Йәгез, бер дога!**

**АЧУ ЧЫККАНДА УКЫЛА**

Пәйгамбәребез (с.г.с.) ачуы чыккан кешегә тәһарәт алуны, басып торса, утыруны, утырса, ятуны киңәш иткән, ә тагын бер хәдисендә болай дияргә киңәш иткән: «Әгузү билләһи мин әш-шәйтан ир-рәҗим».

*Мәгънәсе:* «Аллаһның рәхмәтеннән мәңгегә куылган шайтанның начарлыгыннан Аллаһка сыенам». (Мөслим, Бирр: 30)

**:: Кичерә алмаслык үпкә, гөнаһлар бармы?**

– Җир йөзендә фәкать бер генә гөнаһ – Аллаһы Тәгаләгә тиңдәшлек кылу гына гафу ителми. Калган барлык гөнаһлар, шул исәптән үпкәләтү дә кичерелергә тиеш. Аллаһы Тәгалә – иң рәхимле, иң шәфкатьле. Кеше нинди генә гөнаһ кылса да, Ул аларны гафу итә. Раббыбыз шулкадәр рәхимле, шәфкатьле икән, үзебезне тәкәббер, горур итеп тоеп, кешене гафу итмәскә ни хакыбыз бар?! Киресенчә, без шушы тәкәбберлегебезне сындырып, гафу сорап килгән кешене кичерергә тиеш.

**:: Шулай да гафу сорап килгән кешене кичермәү гөнаһ буламы?**

– Гафу сорап килгән кешене кичермәү гөнаһ түгел. Әмма мөселман кешесенә болай эшләү дөрес булып бетмәс. Ничек кенә кыен булса да, кешене гафу итәргә тырышырга кирәк. Кайчак шул рәвешле үз-үзеңне җиңү дә мөһим. Кешене Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен гафу итәм дип әйтергә мөмкин. Бу адымың синә һичшиксез савап булып язылачак.

## *Хәерле булуны максат ит*

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең бер хәдисендә: «Бу дөнья вакытлы гына кулланырга бирелгән. Файдалану өчен алырга мөмкин булган нәрсәнең иң яхшысы – тугры хатын», – дигән. Изге хатыннар – ирләренә итагать итүчеләр. Сезнең һәркайсыгыз көтүче, һәркайсыгыз үз көтүе өчен җавап бирәчәк. Ир кеше гаиләсе өчен булса, хатыннар – йорт-җирне һәм балаларны күзәтеп торучы.

Пәйгамбәр Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер көнне сәхәбәләре арасында утырганда: «Сез хәерле гаилә башлыгы булыгыз», – дип әйтте. Сәхәбәләр: «Ул ничек була соң?» – дип сораган. «Сез өегезгә кайткач, хатыныгыз куанса һәм сөенсә, балаларыгыз сезнең кочагыгызга ташланса, димәк, сез – хәерле гаилә башлыгы», – дигән. Әгәр сез ишектән кергәч тә, хатыныгыз турсаеп: «Әнә кайтты», – дип борын астыннан мыгырданса, балаларыгыз почмакка качса, сездән ераклашуны яхшырак дип уйласа, белегез, сез хәерле гаилә башлыгы була алмассыз», – дигән.

Хатыннар өчен дә шулай. Сез дә өегездә хәерле хатын булыгыз. Сәхәбәләр: «Хәерле хатын нинди була ул?» – дигәннәр. Пәйгамбәр: «Ире хатынының йөзенә караса, ул үзен рәхәт хис итә», – дигән. Аллаһы Тәгалә ирләргә яхшы хатын бирсә, аның ярты мәшәкатенә ярдәм итүче буладыр, калган яртысын үзе башкарыр. Ирне ир иткән дә хатын, хур иткән дә хатын, диелә. Иренә һәрвакыт ярдәм иткән, аңа кундәм булган, аны үстерә торган хатын аның тормыш тераге, юлдашы була. Әгәр инде иренә һәрчак каршы килеп, үз мәнфәгатен генә кайгыртып яшәгән хатын иренең тормышын гына түгел, гаиләсен, балаларының да киләчәген бозачак. Тавыш, гауга, бер-берсенә дошманлык булган өйдә рәхәтлек булмау һәр кешегә мәгълүм. «Адәм балаларына парлашып яшәү, үзара мәхәббәт – Аллаһы Тәгалә тарафыннан әмер ителгән шарт», – дигән пәйгамбәребез.

Аңлашып яшәүче ир белән хатын үзләренә генә хас серләрен, нечкәлекләрен төшенеп яшәүче тыныч гаилә барлыкка китерәләр. Әгәр кешегә бирелгән әхлак югалса, тормыш рәхәтлеге дә югалачак, билгеле.

Шәрифулла САФИУЛЛИН.

*(«Әхлакый тормыш» китабыннан өзек)*

**Кыйсса**

## Бәхет үзе таба

Бәхет дөнья гизеп, үз юлында очраганнарның бөтен теләген үтәп, кешеләрнең барчасына да бәхет өләшеп йөргән. Шулай берчак ул саксызлык белән тирән бер чокырга төшеп киткән һәм аннан күпме генә тырышса да, чыга алмый азапланган. Чокыр янына теләкләрнең чынга ашуын үтенгән кешеләр килә һәм китә торган. Бәхет аларның һәрбер сорагаын үтәгән.

Бервакыт чокыр янына яшь кенә бер егет килгән. Ул, бәхетне күрсә дә, аннан берни таләп итмәгән. Киресенчә, үзе: «Син, бәхет, ни телисең?» – дип сораган. «Әлеге чокырдан чыгар идем», – дигән бәхет. Егет аны тартып чыгарган да үз юлында булган. Ә бәхет бер адым да калмый аның артыннан йөгергән. Төптән уйлап карасаң, без бәхетне түгел, бәхет безне таба.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

# Ә син танийсыңмы?

**Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.**

– Бүген төрле тикшерүләр үткәрү өчен мөмкинлекләр бар. Без баланың сәләтен ачыклау өчен нейрометрия ясыйбыз. Генетикадан берәү дә баш тартмады әле. Аңа да игътибар итәргә кирәк. Бу әти-әни шундый булган, бала да шуны кабатлаячак дигән сүз түгел. Ул сәләт әби-бабайдан килергә дә мөмкин. Безнең үзәккә килүчеләр арасында да бик үзенчәлекле балалар бар. Алар башкача фикерли, кайчан оныталып, «һавага очып» китәләр. Сөйләшү, күзаллау сәләте башка, үз-үзен тотышы белән аерылалар, – ди нейропсихолог.

Нуршат Галимова әйтүенчә, сәләтле балаларны танып, вакытында ярдәм итәргә кирәк. Дөрес ярдәм булмаса, андыйлар югала. Аларны бер кысага кертергә, күрше баласы белән чагыштырырга кирәкми. Шулай ук, олысының холкы шундый, кечесе башка төрле, нишләп алай икән, дип аптырамаска куша. «Ул башка вакытта туган бит. Шуңа күрә шулай. Без балалардан соры масса ясарга тырышабыз», – ди ул.

Белгечнең әти-әниләргә тагын бер киңәше бар: «Бала өчен барысын да хәл итмәгез!» «Аю хезмәте» күрсәтү баланың даһилыгын юкка чыгарырга мөмкин. Шул ук вакытта баладан булдыра алмаганны таләп итмәгез!

### Фикер

**Надир БАҺАВИЕВ, галим, аэрокосмик инженер:**
– Мин – даһи, идеяләрем үзенчәлекле. Әгәр аларга таянсак, дөньяда күп нәрсәгә ирешә һәм Галәмгә дә менә алабыз дип уйлыйм. Татарстан Фәннәр академиясенә бер фәнни мәкалә җибәрдем. Термотөш реактор төзү турында ул. Әгәр аны төзесәк, ул безгә күп итеп энергия бирә, нефть һәм күмергә бәйләнешне киметергә булыша ала. Андый реакторлар әле беркайда юк, аларны бик арзан итеп ясарга була.

Балага юнәлеш бирү өчен, беренчедән, аны тыңларга кирәк. Берничә төрле түгәрәккә алып барып карагыз. Бәлкем, ул арадан бер кызыгын табар. Бу аның талантын ачар. Түгәрәк ул – мәктәптән тыш үсү. Мин кечкенәдән музыка белән шөгыльләндем. Җыр баш мие эшчәнлеген үстерергә булыша. «Сәләт»тә талантлы кешеләр белән очрашуның да файдасы булды. Университетка әзерләнгәндә математика түгәрәгенә йөрдем, үзем дә химияне өйрәндем. Әти-әни дә булышты. Алар миңа конструкторлар сатып алып кайта иде. Бу да үз нәтиҗәсен бирәчәк.

**Алсу ГАТАУЛЛИНА, дәү әни:**
– Хәзер йомырка тавыкны өйрәтә. Балаларыбыз бездән күпкә акыллырак. Оныгыбыз Динә ике яшьтә сөйләшә башлады. «Дәү әни, әйдә, тәмлүшкәләр белән бергәләп чәй эчик әле», – дигәч, аптырап калдым. Әллә нинди фәлсәфи сораулар бирә, кайчак җавап та биреп булмый. «Әти-әниләр өйгә кайтмаса, мин кем белән яшәрмен?» «Биеккә менсәм, аягым сыначак бит». Вәт әкәмәт, өч яшьлек бала вакыйганың ахырын уйлый. Оныкның хикмәтле булуына карап, кайвакыт куркып та куям. Болыннан чәчәк җыйганда, сабагын сыпырып, матур итеп җыя. Каян белә диген син аны? Үзенчәлекле бала. Үз балаларым андый түгел иде. Әти-әниләре юристлар булганга, шулай акыллымы икән – белмим. Аны хосусый татар-инглиз бакчасына бирдек. Әлбәттә, акыллы булуын телибез. Һәр кеше шулайдыр инде ул. Хәзер бит мөмкинлекләр бар. Нигә шуннан файдаланмаска? Акыллы, тәрбияле баланың әти-әнисе, әби-бабасы булу – горурлык дип саныйм.

Илдар Мөхәммәтҗанов

# ГҮЗӘЛЛЕКНЕ БЕРӘҮ ДӘ ҖИМЕРМИ

Һәр йортта берәр Фәүзия яшәсә, бар җиребез балкып торыр иде. Казанның Әпсәләмов урамындагы 28 нче йортның ишегалды иртәнге яздан кар төшкәнчегә кадәр аллы-гөлле чәчәкләргә күмелеп утыра. Шушы йортта яшәүче Фәүзия Хәйруллинаның тырышлыгы нәтиҗәсе бу. «Матурлык белән генә кешене тәрбияләп була», – ди ул. Гүзәллеккә кул сузучыларны да тәртипкә өйрәткән, хәзер аның чәчәген берәү дә рөхсәтсез өзми.

Менә унбиш ел инде аның өй каршындагы бакчага чыкмыйча калган көне юк. Ике сәгать вакыты шунда үтә. Торактан файдалану идарәсендә (ЖЭУ) идән җыештыручы булып эшли ул, моңа кадәр 20 еллап урам себергән. Үзе Саба якларыннан. Улы гаиләсе белән яши. Чисталык яраткан ханым тирә-юньне матурлыкка күмәргә булган. Чәчәк үстерү җанга тынычлык бирә, ди. Быел чәчәкләр бәйгесендә беренче урынны алган икән.

– Без бу йортка килгәндә, бакчаның коймасы юк иде. Кешеләр тәрәзә төбеннән сукмак ясап йөрде. Болай булмас дип, мәрхүм ирем белән бакча ясадык. Анда чүп үлән үстереп булмый бит инде. Башта мальва утырттым, тик ул бөтен җирне басты. Аны чистартып башка чәчәкләр утырттык. Базарга чыккач, виноград үсентесе күрдем. Сатып алмыйча түзә алмадым. Башта үсмәде, хәзер шаулап утыра. Җимешне дә мулдан бирә. Балалар рәхәтләнеп ашый, – ди 59 яшьлек Фәүзия апа.

Лаләләрне бик ярата икән. Ирис, флокс, нәркиз, петуния, гортензия, ромашка, кукчәчәк. Чәчәкләрнең нindие генә юк. Иң түрдә – көнбагыш. Җил тегермәне, шарлавык, гөмбәләр белән дә бизәгән бакчаны. Затлы роза, лилияләрне утыртып караган, тик «озынкул»лар тамыры белән умырып алып киткәннәр. Бу хәл күптән булган инде. Шуннан бирле бары гади чәчәкләргә генә өстенлек бирә. Аларга сокланып китүчеләр күп икән.

– Теләгән һәр кеше үз бакчасын шулай гүзәл итә ала. ЖЭУ орлыгын да, чүлмәген дә, туфрагын да бирә. Суны да көйләп куйдылар. Бакчаны карарга вакыт һәм тырышлык кирәк. Иртә белән су сибәм, ашлыйм. Эшемнең нәтиҗәсен күрү, күршеләрдән, йорт янәшәсеннән узып китүчеләрдән рәхмәт ишетү рәхәт, – дип елмая Фәүзия Хәйруллина.

Сәрия МИФТАХОВА

# ҺӨНӘРЛЕНЕҢ ДӘРӘҖӘСЕ КИМЕМИ

**Гадәттә, гаиләдә ире яки хатыны гына һөнәрле була. Дөрес, һәркем үз тормышын үзе көтә. Булдыра алганча ремонтлый-төзәтә, ясый-пешерә... Ә менә авылдашларым Сабирҗановлар гаиләсендә барысы да алтын куллы. Мең дә бер эшне белеп-өйрәнеп туганнар диярсең.**

Әлекке сыйныфташым (хәзер инде авылдашым да) Фәнзәлиянең кул эшләренә һәвәслеге каян килә торгандыр – анысын сораганым юк. Әмма аның оста җиләкче, бәйләүче, чигүче, тегүче икәнен ишетеп түгел, күреп беләм. Блогер түгел ул, әмма кайчакта кызыктырып үзенең сәхифәләренә мичтә пешергән коймакларын, чиләк-чиләк җыйган җиләк-гөмбәләрен, алардан, шулай ук бакчасында үскән җиләк-җимеш, яшелчәләрдән ясаган төрле кайнатма-салатларын куеп сокландырып ала.

Бакчасында үскән суганны да ул башкалар кебек сетка-тартмаларда сакламый, әбиләр заманындагы кебек, «баулап» кую ярата. «Нократ Аланында эшләгәндә Кукмара районының Адай авылына кунакка кайтып йөрдем. Суган бауларга шулардан өйрәнеп калган идем», – ди үзе. «Баулаган» суганнары фотосын куйган саен сокланып, комментарий язучылар шактый була.

Тик утырырга яратмый. Кулында һәрчак бәйләве булыр. Заказга бик күп балалар киемнәре, башмаклар бәйли, исемнәре үреп язылган мунчалалары да бик популяр. Бигрәк тә балалар мондый бүләккә сөенә икән. Бүләк димәктән, бер елны Фәнзәлия Коръән ашына килгән ике дистәгә якын әбине үзе бәйләгән башмаклар белән сөендергән.

Тормыш иптәше Рафаэль дә бала чактан балта эшенә оста булды. Кечкенә сыйныфларда укыганда ук мәрхүм абыйсы (шулай ук укучы) Равис белән икесе генә койма кора иде инде алар. Тормыш итә-итә, ташчы, калайчы һөнәрләрен үзләштерде. Бүген инде белмәгән бер эше дә юк. Башка чыкканнан бирле бөтен төзелешне ул чакта мәктәп укучысы гына булган улы Фирзәр белән икесе генә эшләделәр. Кайберсен инде ике мәртәбә яңарттылар. Үзе белгән барлык һөнәрне улына иплән кенә өйрәтүе, аны мөстәкыйль тормышка әзерләвен тирә-күршеләре һәрчак сокланып күзәтә иде. Матурлык яраткан (оста рәссам да әле ул) Рафаэльнең эшләгән бар эше пөхтәлеге, уңайлылыгы белән аерылып тора.

Кызлары Вәсилә дә мәктәптә укыган елларында кул эшләре буенча бик күп бәйгеләрдә катнашып, җиңүче булды. Кул эше белән бәйле булмаган бәйгеләрдә җиңәргә дә еш кына әнә шул һөнәрле булуы ярдәм итә иде. Бөтен фантазиясен эшкә җигеп, ниләр генә бәйләмәде, ниләр генә текмәде, ясамады ул. Берсеннән-берсе үзенчәлекле эшләнмәләренә күргән бер кеше соклана иде (моннан дистә еллап элек бу уңган кыз турында язган идек).

Бүген инде Фирзәр белән Вәсиләнең үз тормышлары. Балалар үстерәләр. Әмма ышанам: әти-әни йортында алган күнекмәләр, осталыклар аларга тормышта күп проблемаларны хәл итәргә булышадыр. Алар да балаларын үзләре кебек һөнәрле итү өчен тырышадыр. «Өч яшендә Фирзәргә әти (кайнатасы Муллануp абый шулай ук чын балта остасы иде) бүкән кертеп куйды. Зур күсе коегы (бездә зур кадакларны шулай дип йөртәләр) кадаклар һәм чүкеч бирде. Кагарга өйрән дип. Шуларны кагарга өйрәнә-өйрәнә Фирзәрнең тырнагы да төшкән иде әле», – дип искә ала Фәнзәлия. Тырышлык бушка китми, нинди генә заман, чор булса да, һөнәрленең дәрәҗәсе кимеми.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

# АЛЬБИНАНЫҢ КҮҢЕЛ ЭШЕ

**Теләче районының Иске Җөри авылында яшәүче Альбина Салихова төрле бәйрәмнәргә өстәл әзерләп бирә. Кулында җир милке белгече һәм азык-төлек сәнәгате технологы дигән дипломнары булса да, бу эшен ул күңел эше ди. Каенанасы, каенатасы белән бергә яшәүче килен, ире белән дүрт малай үстерүче ханым ничек бар эшкә дә өлгерә соң? Бәйрәмдә заказга табынны кемнәр әзерләтә? Альбинадан әнә шул хакта сораштык.**

– Мин пешеренергә бик яратам. Электән нинди генә ризык пешерсәм дә, аны социаль челтәрдәге сәхифәмә куеп бара идем. Кайбер чакта ясаган салатларымны, кабымлыкларымны ошатып, заказга ясатучылар булгалый иде. Ә менә табын әзерләү турында уйлаганым да юк иде. Бер тапкыр Саба районына кыз озату мәҗлесенә өстәл әзерләп бирүемне сорадылар. Аны-моны уйлап тормыйча ризалаштым. Табын әзерләп йөрү шул көннән башланды инде, – дип искә ала Альбина. – Кешеләр бер-берләреннән ишетеп, мине чакыра башлады. Корьән ашлары, бәби чәе, килен төшерү, кыз озату, юбилей кебек мәҗлесләргә гел заказларым булып тора.

Менюны заказ бирүче белән бергәләп хәл итәләр. Кемгә нинди ризык кирәк, шуны әзерләп бирә. Киңәшләрен дә кызганмый. Салат табында озак торасы булса, суганлы һәм йомыркалыны әзерләмәү хәерле, мәсәлән.

– Башта өйдә әзерлисен әзерлим, – ди Альбина. – Ризыкларым әзер булгач, чакырган җиргә чыгып китәм. Анда тагын берничә сәгать эшлим. 15–20 кешелек табынга әзер ризыкларны тезеп, бизәп кую өчен 2–3 сәгать вакыт кирәк. Бер табын әзерләр өчен ике көн китә. Әмма үземә эшем ошагач, шулкадәр тиз эшләгән кебек булам.

Альбинаның дүрт малае үсеп килә. Аларны каенатасы белән каенанасы караша икән. Бик кирәк чакта үзенекеләр дә ярдәм итеп тора. Олы улыма ышанырга була, ди үзе. Ул энеләрен карау гына түгел, өйдәге эшләрне дә эшләшә икән. Ире табын әзерлисе җиргә йөртә.

– Кечкенә улым белән декрет ялында саналам. Гаиләгә акча кереп торгач, рәхәт инде. Заказларның күбесе атна ахырына була. Шуңа да өйдәге эшләрне атна уртасында эшләп куярга тырышам. Әти-әнигә, иремә рәхмәт, – ди ул. – Кешегә ярау җиңел түгел. Төрле чаклар була. Бик ошатып калсалар да, ахырдан берәр күңелсез сүз ишетелә. Әмма мин боларны йөрәгемә якын алып тормыйм. Эшемне җиренә җиткереп башкарам. Ни дисәң дә, рәхмәт әйтүчеләр бик күп. Аларның яхшы сүзләре канат куя да инде миңа.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

# ИЛНАЗНЫҢ ТОРМЫШ АДЫМНАРЫ

Балтач районының Салавыч авылында гомер итүче 19 яшьлек Илназ Мәхмүтов турында «Ватаным Татарстан» газетасында берничә тапкыр язма чыккан иде инде. Хезмәттәшебез Гөлсинә Хәбибуллина аның язмышы, ничек яшәве, нинди сынаулар аша үтүе турында бәйнә-бәйнә хәбәр итеп торды. Без яңадан Илназ турында язарга булдык. Язуыбызның сәбәбе – «ВТ» редакциясе үзенең дуслары белән Илназга хәйрия концерты уздыра.

Исегезгә төшереп китик: Илназ 9 нчы сыйныфны тәмамлап, Казанның энергетика техникумына документларын тапшырып кайтканда юл фаҗигасенә эләгә. Казанга алар әнисе Әлфира белән килә. Язмыштыр инде, Әлфира авылына көнендә кайтып китә, ә Илназ шәһәрдә апаларында кала.

– Икенче көнне кәтү чираты, аннан соң каенатамның юбилее иде. Шуңа да иремнең сеңлесе, Илназ безнең белән генә кайтсын, диде. Ул чакта күңелгә начар уй киләме? Апасының юлда азапланып йөрмәсеннәр диюе бит инде, – дип искә ала Әлфира. – Мин ул көнне автобуста кайтып киттем. Икенче көнне өй телефоныбыз шалтырый. Авылдашыбыз икән. «Төрнәле авылы янында юл һәлакәте булган. Мәхмүтов фамилияле кешеләр икән», – дип әйтеп куйды. Йөрәгем урыныннан кузгалды. Бәргәләндем инде. Күңелем нидер сизенә бит! Ә берազдан теге авылдашыбыз яңадан шалтыратып, сезнекеләр икән бит, диде. Ул чакларны искә төшерсәм дә, йөрәк елый. Әле менә бөел гына берәз тынычланып, улымның язмышына риза булдым.

Фаҗигадән соң Илназга төне буе операция ясыйлар.

шәхси архивыннан

Эчәкләре өзелгән була. Хәле катлаулангач, аны Казанга алып китәләр.

– Ул чакта ДРКБга эләктек. Арка миенә зыян килеп, анда шеш хасил булган иде. Хәтта арка миендә кечкенә тишек тә бар иде. Аңа да операция ясарга туры килде. Улымның ашаганы кире чыкты. Табиблар да сәбәбен таба алмады. Илназ, ашый алмагач, ябыкты. Ул вакытта елауларым! Балам өчен бик борчылдым. Көнем – көн, төнем төн булмады. Улым әкренләп уңайланганны күргәч кенә күңелгә җылы йөгерде. Баламның исән калуына сөенеп, шөкер иттем. Инде хәзер бу вакытлар артта калды, – дип сөйли Әлфира.

Бала ялгыз гына йөрми. Аварияда җизнәләре һәлак була. Апаларына да бик озак дәваланырга туры килә.

– Юл фаҗигасендә каршыга чыккан йөртүче гаепле иде. Гаиләбезгә нинди зур хәсрәт китерде ул. Сеңлем балаларын ялгыз үстерә. Улым әле дә сәламәтләнә алмый. Ул йөртүченең йөзенә карарга йөрәгем җитмәде. Шуңа күрә судларга йөрмәдем дә. Аллаһы Тәгалә үзе белер әле, – ди Әлфира. – Улым әкренләп аягына басарга, тотынып йөрергә өйрәнде. Тезләре дә бөгелә. Аллага шөкер, улымның башы эшли, куллары йөри. Кырымга барып дәвалануның файдасын күрдек. Шуңа да дәвалануны туктатасы килми.

Илназ читтән торып икътисадчыга укыган. Киләчәккә матур хыяллары күп аның. Тормыш юлында ныклап атлап барасы, бәхетле гаилә корасы килә. Йөреп китәр өчен тернәкләнү кирәк. Тиздән алар яңадан Кырымга китәләр. Анда дәвалану өчен 500 мең сум акча сорыйлар.

Балтач районының Салавыч авылы клубында 2 октябрьдә узасы концертта популяр җырчылар Алсу һәм Азат Фазлыевлар чыгыш ясаячак. Гадәттәгечә алар быел да яңа сезонны изге эш белән башлый. Әлеге концертка килә алмаучылар да Илназга ярдәм кулы суза ала.

Әлфира Гомәр кызы Мәхмүтова исемендәге
Саклык банкы картасы номеры: 4276 6200 4022 4754.
Ул 8 987-401-38-46 телефоны номерына беркетелгән.

# ТИКТОРМАС АЙНУР

**Көчле рухлылар**

**Җитте өйдә утырырга! Мамадышта яшәүче Айнур Мөхәммәтшин әнә шулай дип кеше арасына чыга. Тумыштан аяклары авыру булган егет 17 яшенә кадәр арбада гына утырып йөри. Ә аннары протез кигәч, култык таягына таяна.**

шәхси архивыннан

– 7 нче сыйныфта укыганда, шәһәр көнен бәйрәм итәргә бардык. Мәйданга чыгып бии башладык. Күз алдына китерәсезме: икебез арбада утырган килеш селкенә, икебез үз аякларында бии. Әнә шунда безне күреп калганнар да, эзләп өйгә килделәр. Мәктәпкә укырга чакырдылар. Аңа кадәр белемне өйдә генә алдым, – дип сөйли Айнур. – 3 нче мәктәп директоры Фәнис Мөхәммәтҗановка чиксез рәхмәт. Ул мине үзе килеп чакырды. Үз баласыдай якын итте. Хәтта үз машинасында мәктәпкә алып бара, кире кайтарып куя иде. Әкренләп үзем генә йөрергә өйрәндем.

2015 елда Айнурның әти-әнисе улларының аякларына протез ясатырга дигән уйга килә. Акчасын да табалар, җитмәгәнен укытучылар җыеп бирә. Инде протез әзер булгач, Айнур куркып кала. Янәсе, коридорда балалар бәрелсә, егылырмын дип уйлый. Укытучылар киңәше белән ул протезларны башта түгәрәкләргә барганда кия башлый, аннары ияләнеп китә, салмый да. Остару җитә, республикада узган күп кенә спорт ярышларында катнашып, җиңүләр дә яулый әле ул.

Тормышта ирешкән уңышлары өчен Айнур укытучыларына рәхмәтле. Әгәр алар үзләре өенә килеп укырга чакырмаган булса?! Яшьтәшләре белән аралашу, алардан калышмаска тырышу егеткә канат куя да инде. Әгәр өйдә генә утырган булса, институтка да кермәгән булыр иде.

– Миңа КФУның Алабуга филиалына укырга керергә тәкъдим иттеләр. Шөкер, үзем теләгән технология булегенә керә алдым. Тулай торакка әтием урнаштырды. Беренче каттан булмә алу бәхетенә ирештек, – дип искә ала Айнур. – Укып бетергәч, районыма кайттым. «Квантум» үзәге ачылаcын белгәч, эш сорап шунда килдем. Берсүзсез алдылар. Хәзер биредә «Робототехника», «Модельләштерү», «Яшь электрчы» түгәрәкләрен алып барам. Һәр түгәрәккә 15әләп бала йөри.

Айнур 2018 елда машина йөртү таныклыгы да алган. Хәзер инде «тимер ат»ын икенчегә алыштырырга да өлгергән. Кул белән идарә итә торган машинада җилдерә ул.

– Бу көннәрне күрә алганым өчен әти-әниемә, дусларыма рәхмәт. Мине беркайчан да, син мондый, син тегенди, дип кыерсытмадылар. Мәктәптә дә начар мөнәсәбәт сизмәдем. Укыганда да дусларым яхшы булды. Әнә шуңа да мин бер дә кимсенмәдем. Көчле рухлы, батыр итеп үстергәннәре өчен әти-әниемә рәхмәт. Алар беркайчан да теләкләремә каршы килмәде. Нәрсә генә эшләсәм дә, син булдырасың, дип тордылар. Аларның ышанычы мине көчле итте, – ди ул. – Физик мөмкинлеге чикләнгән кешеләргә киңәшем шул: бер урында тик утырмагыз. Үзегезгә ниндидер шөгыль табыгыз. Оялып, кимсенеп бушка вакыт уздырмагыз. Күңелдә уйлар, хыяллар булырга тиеш. Алар булса, вакыт та җитмәячәк. Киләчәктә бик зур хыял белән яшим. Үз тиңемне табып гаилә корасым, балалар үстерәсем килә. Бу теләгем дә тормышка ашса, дөньям түгәрәкләнер иде.

**Кайтаваз**

## БАЛА ХӘСРӘТЕ ЯЗМАСЫН!

№ 135 | 16 сентябрь | 2022 КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ ҖЫЛЫ? ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

АВЫРУ БАЛА ӘНИСЕ:
«БЕЗНЕҢ ХӘЛНЕ АҢЛАУЧЫ СИРӘК»

**«Төенчегем үземнән калмасын дип телим». Азнакайда гомер итүче Алсу Фәрхетдинова әнә шулай ди. 19 ел элек гаиләләренә килгән сынауны баштарак кабул итәргә теләмәсә дә, соңрак язмышына риза була ул. Бәргәләнеп, елап, өзгәләнеп берни эшли алмаячагын аңлый. Бар көчен җыеп, сабыен ничек бар шулай кабул итеп яшәргә өйрәнергә туры килә аңа.**

Әбит бәби көткәндә барысы да яхшы була.

– Алиябезне көтеп алдык. Яңа гына тормыш башлаган чак. Табиблар, кызыгыз булачак, дигәч, ничек шатланганымны белсәгез иде! Шулкадәр көттем мин аны, – дип башлады сүзен Алсу. – Әмма сөенеч озакка бармады. Сабыемны бик авыр таптым. Үз хәлем яшәү белән үлем арасында иде. Ә кызымны күрсәтмәделәр. Нидер бардыр дип уйламадым да. Аны реанимациягә алып киттеләр. Ул анда биш көн яткач, мине өйгә озерли башладылар. Бик курыктым. Шуннан соң безне Казанга җибәрделәр. Башкала табиблары да сөендермәде, соңга калгансыз, диләр. Баланың авыру булуы турындагы сүзләрне кабул итә алмадым. Елыйм да елыйм. Ул чактагы халәтемне әйтеп аңлатырлык түгел иде.

Алиядә ДЦПның катлаулы төрен ачыклыйлар. Нерв системасына бик нык зыян килгән була.

– Кызыбыз гәүдәсен дә тота алмый, аяк-куллары да тыңламый. Гел ятып торып, тәне бозылмасын өчен, аркасын ярты сәгать саен уып торам. Көненә бер сәгать кенә

Алия Фәрхетдиновага ярдәм итәргә теләүчеләр өчен исәп-хисап реквизитлары:
Алсу Зявдатовна исемендәге Саклык банкы картасы: 2202200951923489.
Тинькофф картасы номеры: 2200700172954165.
Карталар 89061163520 телефон номерына беркетелгән.

булса да, Алияне махсус арбада утыртып торырга тырышабыз. Балабыз сөйләшә дә алмый. Бары тик башын селкетеп, «әйе» белән «юк»ны гына сиздерә, – дип сөйли әнисе. – 19 ел буе менә шулай яшибез. Минем Алия ту-

ӘТИ НАЗЫ

«Мине оныт...адыгы...

Узган җомга көнне газетабызда 17 яшьлек Алия Фәрхетдинова турында язма басылып чыкты. Әнисе Алсу баласына ярдәм итүләрен сорап мөрәҗәгать итте. Бер атна вакыт узарга өлгермәде, Алсудан җылы сүзләр килеп ирешә.

– Балам язмышына битараф булмаучыларга чиксез рәхмәтемне җиткерәм. Берничә көн эчендә акча салучылар күп булды. Аллага шөкер, без уколга җитәрлек акча җыя алдык. Күңелемдәге сөенечне әйтеп аңлатырлык түгел. Миңа шалтыратып үз киңәшләрен бирүчеләр, хәтта артык уколларны почта аша җибәрербез, диючеләр булды. Балам кайда дәваланса яхшы буласын, нинди тернәкләндерү курслары узарга кирәклеген дә әйтүчеләр булды. Җир йөзендә мәрхәмәтле кешеләр шулкадәр күп икән. Мин моңа тагын бер кат инандым. Һәр кешегә үз яхшылыгы меңләтә әйләнеп кайтсын, – диде ул. – Яңа гына ишек шакыдылар, бик матур итеп киенгән бер ир-ат басып тора. Әлмәттән килгән. Кулында күчтәнәч, пелёнкалар һәм дарулар. Кызымны күргәч елый башлады. Алияне кулларыннан, аякларыннан үбә. Күптән түгел балалары вафат булган икән. Беребезгә дә бала хәсрәте күрергә язмасын.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

## ЛИЛИЯ МӘХМҮТОВА:

# «ТОРМЫШТА – ХӘЛИЛ, СӘХНӘДӘ ИСЛАМИЯ КЫЗЫ МИН»

**Татарстанның атказанган артисты Лилия МӘХМҮТОВАны Тинчурин театрында әнисе Исламия Мәхмүтованың дәвамчысы итеп кабул итәләр. Төскыяфәт белән дә, туры сүзе белән дә дәвамчы икән шул. Без театр проблемалары, төрле тәҗрибәләр, Мәхмүтовлар мирасы хакында сөйләштек.**



Лилия Мәхмүтованың шәхси архивыннан

**:: Яңа сезонны нинди хис-кичерешләр белән каршылыйсыз?**

– Артист һаман өмет белән яши инде ул. Яңа постановкалар, рольләр көтә. Киләсе елга театрга 90 ел тула, әлеге күркәм юбилейны шәп әсәрләр, матур яңалыклар белән каршылыйсы килә.

**:: Элек сезне Хәлил абый кызы дип йөртәләр иде, хәзер Исламия Мәхмүтованың яшь чагы дип карыйлар. Холык белән сез кемгә охшаган? Әти-әни белән чагыштыру үпкәләтмиме?**

– Тормышта Хәлил кызы дисәләр дә, сәхнәдә гел Исламия кызы дип йөрттеләр. Бу минем өчен зур җаваплылык иде. Әнине бөтен Татарстан гына түгел, Россиядә дә беләләр. Безне чагыштыруларны да гаҗәп түгел инде. Төс-кыяфәттә охшашлыклар да бар бит, нишлисең. Әйтик, әнинең «Мәхәббәт чишмәсе» дигән спектакле бар. Соңрак ул анда үзе дә уйнады, мин дә. Шушы спектакльдән соң әнигә: «Исламия, кызың синнән дә уздыра», – дип әйткәннәре булды. Әни, шулаймы, дип сораган була, үзе сөенеченнән балкый иде. Аның горурлануы минем күңелгә дә сары май булып ята. Димәк, бу профессияне юкка гына сайламаганмын.

**– Профессия дигәннән. Сез бит башта артист булмыйм дигәнсез.**

– Әйе шул, мин радиофизик булырга тиеш идем. Шушы юнәлештә 4 ел укыдым да әле. Дүртенче ел киткәч әти-әнигә, мин театр училищесына имтихан биреп карыйм әле, булдыра алмасам, университетта укуымны дәвам итәрмен, дидем. Әни, билгеле, артист һөнәренең бөтен авыр якларын санап китте. Ул чакта әле Тинчурин күчмә театр иде, әни гастрольләрнең 28–30 көн дәвам итүен, балаларга тәрбия һәм игътибар җитмәячәген искәртте. Ярый әле миңа әтиең туры килде, ә синең булачак ирең артист һөнәрен аңлый торган кеше булмаса, дип тә кисәтте. Шөкер, театр мине артист белән кавыштырды. Әти исә әнинең сүзләренә нокта куеп, барсаң бар, әмма бел: бездән бернинди ярдәм һәм синең өчен ялварып барулар булмаячак, диде. Шулай итеп, мәсәл, шигырь, проза әсәре әзерләп, имтихан бирергә киттем. Теләгемә ирештем, Илдар абый Хәйруллин курсына эләктем. Ул мине икенче курска кабул итте. Илдар абый, иртәгә документларыңны алып кил, дигәч, кулыма асыл кош эләккәндәй булды. Театр училищесына укырга керү теләге 17 яшемнән күңелемдә яшәде ләбаса!

**:: Теләк шундый зур булгач, нишләп 4 ел түздегез соң?**

– Мөгаен, үземә башка өлкәдә дә югалып калмыйм дип раславырга теләгәнмендер. Юкса бит, артист баласы артист һөнәрен сайлый инде ул, диярגә яратала. Раславын расладым, әмма университетта укыганның тормышта кирәге чыкмады. Ник дигәндә, техникага өйдә Ренат (Ренат Шәмсетдинов, Татарстанның атказанган артисты. – **Ред.**) хуҗа безнең. Бигрәк дә электрикага бәйле эшләрне ул бик яратып башкара.

**:: Кош тоткандай, зур хыяллар белән театр дөньясына аяк баскансыз. Акландымы ул хыяллар?**

– Ел саен спектакль чыгармасам да, мин беркайчан да эшсез йөрмәдем. Баш режиссер Рәшит Заһидуллин алмаса, башка режиссерлар рольле итте, бер дә булмаса, әни үзе спектакль куя иде. Әмма уйналмаган рольләр бик күп калды. Мин актер буларак ачылып бетмәдем. Классик әсәрләрдә уйнарга кызыга идем. Хәер, Рәшит Заһидуллин Пьер Бомаршеның «Фигаро»сын куйгач, мине Разина роленә сайлады. Ул чакта театрда эшләгән Илдус Фәиз, сине Рәшит яңа спектакленә алган, дигәч, башта ышанмадым. Нинди рольгә, дим. Разина, ди. Олы яшьтәге хатынны уйнарга кирәк була икән, дип уйлап куйдым. Рәшит алай куймады аны. Кызганыч, бу спектакльдә ике тапкыр гына уйнап калдым. Ник дигәндә, бәби көтә идем. И, кызгандым шушы спектакльне. Артист классик әсәрләрдә уйнаганда гына үсә, камилләшә ала.

**:: Актер – режиссерга бәйле һөнәр. Ә сез кайсы режиссерга «бәйле»? Сезне ачкан режиссер дип кемне атыйсыз?**

– Конкрет бер генә кешене атап булмый. Хәтта әни дә мезансценалар куймады. Ул характерны ачып бирә, артист исә үзе «ит кундыра». Мин кемдә генә эшләсәм дә, образларыма үзем «ит кундырдым». Режиссер скелетын ясый, калганы чынлыкта актер эше инде аның. Гәрчә гәүдә борылышларына кадәр куеп биргән рольләр дә була. Миңа андый рольләрдә уйнарга туры килмәде.

**:: Соңгы берничә елда Тинчурин театры үзгәрә. Монда берничә режиссер эшләп карады, спектакль-тәҗрибәләр куелды. Бу – Исламия Мәхмүтовалар чорына нокта куелды, яңа чор башланды дигән сүз дә. Сез элекке чорны нинди хисләр белән озатасыз, яңасын ничек каршы аласыз?**

– Сагыш белән озаттык, сагынып искә алабыз. Миңа калса, ул чор Тинчуринның күтәрелеш чоры иде. «Итил суы ака торур» (Нурихан Фәттах), «Кураж ана һәм аның балалары» (Бертольд Брехт), «Сүнгән йолдызлар» (Кәрим Тинчурин) кебек тирән әсәрләр вакыты иде ул. Хәзер ул дәрәҗәдәге пьесалар да язылмый, куелыш та тирәнлектән шоу ягына авыша сыман.

**:: Театрның киләчәге өметлеме?**

– Өметле дип ышанасы килә. Өметсез – шайтан, диләр бит.

**:: Театрга тәҗрибәләр кирәкме?**

– Әгәр нигезле булса, әлбәттә, кирәк. Әйтик, менә бездә «Башмагым» спектакле классик стильдә дә, джаз стилендә дә куелды. Мин аның ике вариантын да кабул иттем. «Назлы кияү» дә төрлечә куелды. Икесен дә тамашачы яратты. Ә инде нигезе булмаган өтек-төтек тәҗрибә икән, анысы театрны алга җибәрә дип уйламыйм. Нинди генә тәҗрибә булса да, аның умырткасы булырга тиеш. Умырткасы булган тәҗрибә тора-бара тулы канлы спектакльгә әйләнә ала. Мәсәлән, лабораториядә «Кияү урлау» белән катнаштык, ахыр чиктә ул кызыклы спектакльгә әйләнде. Резедә Гарипованың «Карурман»ы ахыр чиктә спектакльгә әйләнде. Чөнки фикере бар, тамашачы аннан нәрсәдер алып китә.

> Яшәү катлауланган саен тамашачы классик әсәрләргә күбрәк тартыла. Мөгаен, анда мәңгелек сорауларга җавап булгангадыр. Ә заманча спектакльләр күбрәк ярсытуга корылган. Нәрсә булды соң әле бу, башым авыртып чыкты, ди икән, ул андый нәрсәгә башка бармый инде. Кеше барыбер театрга энергия алырга килә.

Театрга тәҗрибәләр репертуарда тотып торырдай спектакльләр булганда килешә. Ул чакта, мәсәлән, фестивальдә йөрерлек тәҗрибә-спектакль куярга мөмкин. Ә инде репертуарың элекке спектакльләрдән торса, аларны алмаштырырдай яңалары тумаса, тәҗрибәләргә иртәрәк әле. Аның өчен аякка ныклап басарга кирәк.

**:: Беренче ролегез «Резедәкәй» спектаклендә Резедәме әле?**

– Юк шул, күпләр шулай ялгыша. Минем беренче ролем Илдар Юзеевның «Минем әти мировой» дигән спектакльдә иде. Аны укытучым Илдар Хәйруллин куйды. Без анда курсташым Илсөяр Сафиуллина белән апа-сеңелне уйнадык. Мин – Рево, ул Люция булды. Рево – шук, кызу канлы, кыскасы, сеңлем Ләйсән характерындагы кыз. Тормышта өлгесе булгач, аны уйнау читен булмады. Гәрчә үземдә андый холык булмаса да.

**:: Сезгә бит лирик рольләр күбрәк килешә...**

– Илдар Хәйруллин да шулай әйтә иде. Әмма тора-бара үзе дә шундыйрак рольләр биреп карады. Ул гына түгел, «Хуҗа Насретдин»да – Гөлбану, «Мәхәббәт чишмәсе»ндә Зәмзәмиям бер дә төшеп калган хатыннардан түгел, чаялар, шуклар. Артист һөнәре үзеңне төрле яктан сынап карау белән кызыклы бит инде ул.

**:: Ләйсән белән сез – театрда Мәхмүтовлар династиясен дәвам итүчеләр. Ә сезнең балаларыгыз нишләптер башка өлкәне сайлаган.**

– Баламның артист булуын мин үзем теләмәдем. Гәрчә Ришатның теләге дә, таланты да булса да. Ул музыка мәктәбен бик яхшы билгеләренә тәмамлады, төрле конкурсларда җиңде. Алга таба театр училищесында укырга теләде. Шунда артистның нинди бәйле һөнәр булуын аңлатырга туры килде. Режиссер күзенә күркәм булып күренмәсәң, ролең булмаячак бит. Ир кешегә эшсезлек икеләтә авыр ул. Аңа андый язмыш теләмәдем. Ул төп эшеннән кала мультфильмнар тавышландыра. Күңел эше дип йөри аны-сын. Белгечлеге буенча программист.

**:: Театрда Мәхмүтовлар рухы яшиме әле?**

– Белмим…

**:: Музейда әти-әниегез почмагы бар, мәсәлән. Исламия апаның грим бүлмәсе якты истәлекләрне саклыйдыр.**

– Әни бүлмәсендә матур почмак булдырасы килгән иде. Анда Хәлил Мәхмүтов, Наил Шәйхетдиновның һәм вакытсыз киткән башка актерларның ядкәрләрен дә урнаштырып булыр иде. Аларның һәрберсенең шәхси әйберләре җитәрлек, бай булыр иде. Әмма барып чыкмады.

**:: Хәзер ул бүлмәдә кемнәр урнашкан?**

– Режиссер ярдәмчеләре. Әни соңгы көннәрендә, Ләлә Миңнуллина белән Зөләйха Хәкимҗанова керсен минем бүлмәгә, дип әйтеп калдырган иде. Ләкин… Хәер, без булдыра алганча, әти белән әнинең мирасын саклап, аларның эшләрен булдыра алганча халыкка җиткерергә тырышып яшибез. Әти белән әнигә соңгы бүләгебез – икесенә бергә куелган кабер ташы булды. Аны сеңлем белән бергәләп үз акчабызга ясаттык. Аларның хезмәте онытылмасын иде инде.

> Исламия Мәхмүтова стационар театрда 30 елдан артык эшләде, режиссер буларак 10 спектакль чыгарды, күпме әсәрне тәрҗемә итте. Театрда нинди өлкәдә кытлык, шуңа җиң сызганып тотына иде ул. Ләкин дәүләт тарафыннан бу эшләре игътибарсыз калды… Гомуми эш стажы гына да –56 ел. Әти исә сәхнәдә 46 ел эшләде, театр дип янды дисәң дә була. Безнең нәсел-нәсәпнең театрда гомуми эш стажы 172 елны тәшкил итә.

**:: Гадәттә юбилейда үткәннәргә карап шөкер итәләр, алга план-максатлар билгелиләр? Сез нинди уй-ниятләр белән яшисез?**

– Бу болгавыр вакытта планнар төзеп яшәп буламы икән? Элек мин дә ярты елга, бер елга план төзи идем. Әти спектакль вакытында инсульт алгач, тормышка карашым үзгәрде. Мин хәзер бүгенге көн белән яшим. Иртән исән-сау уянып, үз аякларымда эшкә чыгып китә алам икән, шуннан да зуррак нәрсә юк. Әти безгә әнә шундый сабак бирде. Әни, исән чакта, иртәгә нишлибез, дип сорарга ярата иде. Иртән торыйк әле, дип җавап бирә идем. Хәзер шул ук сорауны Ренат бирә, аңа да шул ук җавап. Ә иртән, исән-сау булсак, без икебез дә бик тиз җыенучан. Башыбызга берәр уй килсә, аны ялт итеп эшләп тә куябыз. Театрны, аның тамашачысын яратабыз. Еш кына, без бит сезнең спектакльләрне карап үстек, диләр, хәзер үзләренең балаларын алып киләләр. Димәк, киләчәккә өмет бар.

Әңгәмәдәш –
Гөлинә ГЫЙМАДОВА

*Руфина Фәттахова – фтизиатр-пульмонолог, Татарстанның атказанган табибы, медицина фәннәре кандидаты. 50 елдан артык ГИДУВта (табибларның белемен күтәрү институты, хәзерге Казан дәүләт медицина академиясе) фтизиатрия буенча табибларга белем бирә. 1970–1980 нче елларда «Азат хатын» журналында (хәзерге «Сөембикә») медицина турында язмалары чыгып килә, укучылардан килгән күпсанлы хатларга җавап бирә. Шулай ук 1970 нче еллардан башлап, 10 елдан артык, телевидениедә медицина темаларына багышланган татарча тапшырулар алып бара. Хәзерге вакытта да газета-журналларда төрле темаларга багышланган язмалары чыгып тора.*

## РУФИНА ФӘТТАХОВА

# УТРАУДАГЫ АВЫЛ

## (ТАБИБ ЯЗМАЛАРЫ)

Мәсәгут – ике урамнан торган гаҗәп матур авыл. Авылны ике ягыннан уратып таррак кына елга ага. Елга буенда әрәмәлек, ямь-яшел болын. Авыл Сабан туе шунда уза. Язгы ташу вакытында елга ярларыннан чыга, авылга керә торган күперне һәр елны диярлек боз ташкыны алып китә дип сөйләделәр. Су бөтен үзәнлеккә тарала, авыл су уртасында утрау булып кала икән. Боз киткәндә бик ямьле була ди: яшьләр гармун уйнатып боз киткәнне күзәтә, кайбер кыюраклары боз өстендә салам учак яндырып, йөзеп тә баралар, имеш. Төнгә кадәр халык бәйрәм итә ди. Ел саен шулай буладырмы, белмим, әмма бу хәл мин анда эшләгән язны булды.

Без эшләгән һәм яшәгән йорт елгага бик якын иде. Төне буе гүелдәү, күк күкрәвенә охшаш шомлы тавышлар ишетелде. Санитарка бик иртә килеп, үкенгәнрәк тавыш белән: «Их, боз кузгалганын күрә алмадык, төнлә башланган», – дип сөйләнеп, безне ашыктыра башлады. «Әйдәгез тизрәк, иң кызыгын күрми каласыз бит», – дигәч, без дә күпергә таба йөгердек. Без баргада күпер әле исән иде, ләкин аның җимереләсе көн кебек ачык, баганалары менә авам, менә авам дип селкенеп тора. Зурзур бозлар килеп бәрелә торгач, күпер ауды, аның такталары, бүрәнәләре агып та китте. Су болынга таба җәелгәннән-җәелә бара. Икенче көнне елга тирәсен танырлык түгел иде, аргы ягының яры күренми дә. Авыл утрау булып су уртасында калган. Мондый матурлык атна-ун көнгә сузыла, диделәр. Бүгенге күзлектән караганда, нинди бәйрәм булсын инде – атна-ун көнгә бөтен дөнья белән бәйләнеш өзелә, олы кешеләргә, җитәкчеләргә бу көннәрдә бер дә бәйрәм булмагандыр.

Боз кузгалуның икенчеме-өченчеме көнендә акушерка кыз белән минем өчен бәйрәм тәмам булды – соңгы көннәрен йөрүче авырлы хатынны тулгак тота башлаган. Нэля (акушерка) шунда ук авырлы хатын янына китте. Бераздан мин дә бардым, баланың йөрәк тибешен тыңладым, хатынның пульсын, кан басымын тикшердем. Мин барганчы Нэля боларның бөтенесен дә эшләгән, сәгате-минуты язылган иде инде. Ул кыз бик ышанычлы, белемле акушерка иде – шулай булырга тиеш тә, алар бит акушерлыкка дүрт ел укыганнар. Акушерканың исәбе буенча бала табарга иртәрәк иде әле. Оча сөяге тар булган һәм өлкәнрәк яшьтә беренче баласын табарга җыенучыларны (утыз-утыз биш яшьтә беренче баласын табарга җыенучы хатыннарны акушер-гинекологлар «старая первородящая» дип йөртәләр) яисә йөрәк авыруы булганнарны, ягъни бала тапканда төрле авырлыклар килеп чыгу мөмкин булган хатыннарны районга җибәрергә тиеш идек. Бу хатын «карт»лар исемлегендә иде. Без кичекмәстән районга шалтыратырга булдык. Сельсовет телефоныннан (авылда ике генә телефон – берсе сельсоветта, икенчесе – колхоз идарәсендә) шалтыратып, Бикбулатов фамилияле врачка хәлне аңлаттык. Кайбер киңәшләрен бирде, фәлән-фәлән дарулары бармы, дип сорады. Юк иде бездә ул әйткән дарулар. Аннан җентекләп оча сөягенең размерларын, авырлы хатынның буен, авырлыгын, температурасын, пульсын, баланың ничек ятуын, йөрәк тибешенең күпме булуын һ.б. кат-кат сорады. Барысын да язып барырга кирәклеген әйтте. Тавышы борчулы иде, бу мине шомландырды. Ахырдан:

– Синең янда берәр авыл кешесе бармы? – диде.

– Бар, сельсовет председателе, – дидем.

– Трубканы бир әле аңа, – диде.

«Галимов абый, врач сезнең белән сөйләшергә тели», – дип трубканы аңа бирдем. Озак кына сөйләшкәч, телефон тагын минем кулга күчте. Бикбулатов абый сәгать саен аңа хәбәр биреп торырга кушты.

Сөйләшү тәмамлангач, бераз гына җиңелрәк булып китте кебек, ләкин бөтен җаваплылык безнең өстә бит, ничек бетәр бу эшләр, озакка сузылып, бала үлмәсме?

Бикбулатов абый районда иң аталы врачлардан санала иде. Сугышта ул әсирлеккә эләккән, илгә кайткач, аны бик озак тинтерәткәннәр. Әле мин белгәндә дә, сугыш бетүгә 15 еллап вакыт узуга карамастан, аңа кырын караганнары сизелә иде.

Мин сәгать саен Бикбулатов абыйга шалтыратып, бөтен үзгәрешләрне сөйләп тордым, аның киңәшләрен акушерка Нэляга җиткерә тордым. Таң алдыннан башланган тулгак тоту кичкә таба бөтенләй сүлпәнәйде, бетте диярлек. Нэля артык борчылмый кебек, Бикбулатов абый да: «Ярый, бераз ял итсен, йокласа, борчымагыз», – диде һәм баланың йөрәк тибешен язып барырга кушты. Төн җитте. Тулгак тоту яңадан бераз көчәйде кебек, баланың чәче дә күренә башлады, юк бит, булмый, тартып алып булмый. Инде баланың йөрәк тавышы да ишетелми кебек – әллә аның йөрәге тибә, әллә үземнең кан тибеше, белмәсең.

Соңгы шалтыратканда минем тавыш бик төшенке, өметсез чыкты кебек. Бикбулатов абый, шактый катгый итеп:

– Сеңлем, хатынны исән калдырырга кирәк, трепанация ясарга туры килер, – диде.

Нишләптер, бу сүзне ишеткәч, әллә ни курыкмадым. Училищедә хирургиядән безне нейрохирург укытты. Бу фәнне беркайчан да класста утырып укымадык, ул безне һәрвакыт больницага, үзе эшләгән бүлеккә алып кереп, операция ясаганда карап торырга куша иде. Баш сөяген тишеп, кисеп, баш миендәге шешләрне алганнарын күп күрдек без. Дөресен генә әйткәндә, институтта укыганда ул хәтле күрергә туры да килмәгәндер. Ә бу очракта, әтәге баланың башын тишеп, аны тизрәк тартып алу турында сүз бара иде. Ягъни хатынны исән калдыру өчен баланы корбан итәргә туры килә дигән сүз. Мин инде хатын янына барышлый ук пункттан кирәкле инструментларны ала бардым. Барып җитү белән моны Нэляга әйттем.

– Юк, – диде Нэля, катгый итеп, – бала әле исән, бар чакыр ирен, ул безгә булышырга тиеш!

Нишләргә җыена бу хохол кызы Бикбулатов абыйдан узып?! Үз акылындамы…

– Бар телефонга, әйт Бикбулатов абыйга, мин ул кушканча эшләмәячәкмен! – димәсенме.

Тагын телефонга йөгердем, тотлыга-тотлыга аңлатырга тырыштым кебек.

– Сеңлем, хатынны исән калдырырга тырышыгыз, калганын акушерка ничек әйтә – шулай эшләрсез, – дигәне генә аңлашылды.

Мин кире барганда бала инде туган иде, тик ул гадәттәгечә кызыл түгел, әллә нинди караңгы зәңгәр төстә булып күренде. Нэля аңа суккалагач, нәзек кенә тавышы да чыкты. Мин баланың кендеген кисеп бәйләгәч, хатынның корсагына җиңелчә массаж ясап, соңгылыгын чыгарырга булыштым, ире җылы чәй эчерде. Нэляның кушуы буенча, баланы төреп, грелкалар белән төрле ягыннан җылытып, мендәргә салып куйдык. Шулай итеп тәүлек буе азаплана торгач, бәләкәй генә малай туды.

Бик озак төпченгәч, пунктны тапшырып, Мәсәгуттән киткәндә генә, Нэля баланың ничек туганын сөйләде. Бикбулатов абый, инде бүтән әмәл калмаса, хатынны үлемнән саклап калу өчен, баланың башын тишеп, аны кул белән тартып алырга кушкан иде. Ә Нэля үзенчә эшләгән: хатынның ирен чакырып кертеп, аңа нишләргә тиешлеген аңлаткан. Тулгак тотканда, ир куллары белән хатынының корсагына басып, балага чыгарга булышкан, ә тулгак арасында акушерка баланы кире этеп, баш юнәлешен үзгәртергә тырышкан, кулын әчкә тыгып, чыгу юлын да киңәйткән.

Туганда юньләп тавышы да чыкмаган сабый тернәкләнеп китте, сау-сәламәт үсте, диделәр. Мин ул авылдан киттем, Бикбулатов абый тәкъдиме белән, район больницасының бала табу бүлегенә акушерка итеп алдылар. Бер елдан мин инде медицина институты студенткасы идем.

# ЕЛЛАР һӘМ ТУЙЛАР

## Өйләнешү – яшел туй

**1 ел – ситцы туй**
2 – кәгазь туй
3 – тире туй
4 – киндер туй
**5 – агач туй**
6 – чуен туй
7 – бакыр туй
8 – калай туй
9 – фаянс туй
**10 – аккургаш туй**
11 – корыч туй
12 – никель туй
13 – челтәрле туй
14 – ахак (агат) туй
**15 – бәллүр туй**
16 – топаз туй
17 – гөлчәчәк туй
18 – фирүзә туй
19 – гранат туй
**20 – фарфор туй**
25 – көмеш туй
**30 – энҗе туй**
35 – мәрҗән туй
**40 – рубин туй**
45 – сапфир туй
**50 – алтын туй**
55 – зөбәрҗәт туй
**60 – бриллиант туй**
65 – тимер туй
**70 – бәрәкәт туе**
80 – имән туй
**100 – кызыл туй**

## Әз-мәз мәзәк

* * *

Әгәр сезгә бәхет елмайды икән, шатланырга ашыкмагыз. Бәлки, ул сездән көләргә җыенадыр?

* * *

42 нче размерлы аяк киеме иң уңайлысы! Кысмый да, төшеп тә калмый. Башка размерлы аяк киемен алучыларга шаккатам мин! Ник аласы сез аларны?

* * *

Бәдрәфтә берәү телефоннан сөйләшә:
– Сәлам.
– Сәлам.
– Нихәл?
– Әйбәт кенә.
– Карале, мин сиңа яңадан шалтыратыйм әле, ату монда күрше кабинкадан берәү минем сорауларга җавап биреп утыра.

* * *

Безнең илдә машина ишеген шапылдатмый гына ябалар һәм ябып бетерә алмыйлар. Чөнки һәр кешенең балачакта әтисе машинасы ишеген каты япканы өчен сыртына эләккәне бар.

* * *

Әгәр дә кибеттә сезгә нидер ошамый икән, бөтен ачуыгызны кассирга чыгарыгыз. Кассир ул шушы кибетнең хуҗасы да булырга мөмкин бит.

* * *

Мин берәр кайчан балаларым туена киләчәкмен дә, табындагы җылы ризыкны ашамыйча, нагетслар һәм чипсы сораячакмын.

# Беләсең килсә...

**1 Ма Сюсиань исемле кытай әбисе 102 яшендә нинди мөгез чыгарган?**
а) мотоцикла 6 машина аркылы сикергән;
б) 8 нче тапкыр кияүгә чыккан;
в) беренче сыйныфка укырга барган.

**2 «Мәргән» сүзе нәрсәне аңлата?**
а) гадел хаким;
б) ерак юлга чыгучы;
в) төз атучы.

**3 Корьәнне рус теленә тәрҗемә иткән Валерия (Иман) Порохова кайсы шәһәрдә туган?**
а) Новокузнецк;
б) Ухта;
в) Надым.

**4 Туры почмаклы өчпочмакның иң озын ягы ул:**
а) гипотенуза;
б) биссектриса;
в) катет.

Җаваплар: 1. в); 2. в); 3. б); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

**Сканворд җаваплары**

**Горизонталь:** утын, ультиматум, Еники, ияр, йозак, кайчы, Аксу, Лиана, Идиот, Янка, ызан, еш, БелАЗ, КАИ, Рамилә, Пи, ел, Ян, туа, аршын, пуант, Лариса, МТС, Ла, батыр, Тамчы, га, Норд, АИ, гарип, әзмәвер, Уно, ир, зөбәрҗәт, әлифба, турник.

**Вертикаль:** чикерткә, Нәргизә, тояк, шау, рация, мал, риба, он, Чаткылар, порт, янчык, Илтани, ас, әҗәт, укытучы, праймериз, ТУ, Ли, биш, ми, ымлык, бәрән, та, Лента, ал, ефәк, Йолдыз, Муса, Вил, тузганак, наян, АН, Максат, Интернационал.

**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
**Индекс П2435**
**Тираж – 15890 данә**
**Газетага сертификат бирелде**
Заказ 339

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
**www.vatantat.ru**
**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**
**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР
**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-67** – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
**222-09-73, 222-09-69, 222-09-65** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
**222-09-67** – дин, сәламәтлек
**222-09-64** – әдәбият, сайт
**222-09-66** – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+